Л.И. Сәүбәнова Ә.С. Тайсин

ГЕОГРАФИЯ

ТЕСТЛАР

8 сыйныф

«Мәгариф» нәшрияты

Л. И. Сәүбәнова, Ә. С. Тайсин

РОССИЯ ГЕОГРАФИЯСЕ БУЕНЧА ТЕСТЛАР

Татар урта гомуми белем мәктәбенең
8 нче сыйныфы өчен

Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Казан
«Мәгариф» нәшрияты
2003

УДК 373.167.1
ББК 74.262.6я72
С93

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Сәүбәнова Л. И., Тайсин Ә. С.

С93 Россия географиясе буенча тестлар: Татар урта гомуми белем мәкт. 8 нче с-фы өчен.— Казан: Мәгариф, 2003.— 80 б.
ISBN 5-7761-1273-7

Әлеге ярдәмлектә контроль һәм йомгаклау тестлары тупланган. Алар һәр тема буенча укучыларның белемнәрен тикшерергә һәм курсның йомгаклау дәресләрен үткәрергә ярдәм итәчәк.

БЗ—9(68)—55—2002/2003

ISBN 5-7761-1273-7

© «Мәгариф» нәшрияты, 2003

I нче вариант

1. Географик атамаларга аларның географик урынна-рын туры китереп җавап бирегез:

Географик атама:	Географик урыны:
1. Базардюзю тавы.	А. Россиянең иң төньяк ноктасы.
2. Дежнев борыны.	Б. Россиянең иң көньяк ноктасы.
3. Челюскин борыны.	В. Россиянең иң көнбатыш ноктасы.
4. Балтыйк комборыны.	Г. Россиянең иң көнчыгыш ноктасы.

2. Бу дәүләтләрнең кайсылары Россия белән коры җир буенча чикләшә?

1. Әрмәнстан, Төркмәнстан, Һиндстан.
2. Украина, Эстония, Корея Халык Демократик Республикасы.
3. Болгария, Төркия, Әфганстан.

3. Административ-территориаль берәмлекләргә алар-ның үзәкләрен туры китереп җавап бирегез:

Административ-территориаль берәмлекләр:	Үзәкләр:
1. Чуваш (Чаваш) Республикасы.	А. Владивосток шәһәре.
2. Хакасия Республикасы.	Б. Чабаксар шәһәре.
3. Приморье крае.	В. Тура шәһәре.
4. Эвенк автономияле округы.	Г. Абакан шәһәре.

4. Мәсьәләне чишегез һәм дөрес җавапны сайлап алы-гыз. Әгәр Анадырь шәһәрендә пояс вакыты көндезге 12 сә-гать булса (төш вакыты), Санкт-Петербург шәһәрендә пояс вакыты күпме булыр?

1. Төнге 12.
2. Иртәнге 5.
3. Иртәнге 3.

5. Мәсьәләне чишегез һәм дөрес җавапны сайлап алыгыз. Әгәр башлангыч меридианда вакыт иртәнге 8 сәгать булса, Тура шәһәрендә (географик озынлыгы якынча 101° кч. оз.) җирле вакыт күпме булыр?

1. 12 сәгать 18 минут.
2. 14 сәгать 44 минут.
3. 15 сәгать 44 минут.

2 нче вариант

1. Россиянең коры җир буенча иң озын чиге кайсы дәүләткә туры килә?

1. Кытайга.
2. Казахстанга.
3. Монголиягә.

2. Бу дәүләтләрнең кайсылары Россия белән диңгез буйлап чикләшә?

1. Алжир, Сүрия, Кытай.
2. Польша, Греция, Германия (Алмания).
3. Эстония, Япония, АКШ.

3. Административ-территориаль берәмлекләргә аларның үзәкләрен туры китереп җавап бирегез:

Административ-территориаль берәмлекләр:	Үзәкләр:
1. Ямал-Ненец автономияле округы.	А. Махачкала шәһәре.
2. Саха Республикасы.	Б. Элиста шәһәре.
3. Калмык Республикасы.	В. Якутск шәһәре.
4. Дагстан Республикасы.	Г. Салехард шәһәре.

4. Мәсьәләне чишегез һәм дөрес җавапны сайлап алыгыз. Әгәр Уфа шәһәрендә пояс вакыты 19 сәгать булса, Николаевск-Амур шәһәрендә пояс вакыты күпме булыр?

1. Төнге 12.
2. Иртәнге 5.
3. Иртәнге 3.

5. Мәсьәләне чишегез һәм дөрес җавапны сайлап алыгыз. Әгәр Иркутск шәһәрендә (географик озынлыгы 129° 43′ кч. оз.) җирле вакыт белән төнге 12 булса, Екатеринбург шәһәрендә җирле вакыт (географик озынлыгы 60° 36′ кч. оз.) күпме булыр?

1. 8 сәгать 2 минут 24 секунд.
2. 9 сәгать 30 минут 40 секунд.
3. 8 сәгать 15 минут 25 секунд.

3 нче вариант

1. Россия территориясе көнбатыштан көнчыгышка бик озынга сузылган, шуның нәтиҗәсе буларак, ...

1. Илдә 3 климатик пояс бар.
2. Климатның континентальлек дәрәҗәсе төрлечә үзгәрә.

2. Бу дәүләтләр арасында кайсылары Россия белән коры җир буйлап чикләшә?

1. Молдова, Венгрия, Словакия.
2. Иран, Гыйрак, Үзбәкстан.
3. Литва, Финляндия, Норвегия.

3. Административ-территориаль берәмлекләргә аларның үзәкләрен туры китереп җавап бирегез:

Административ-территориаль берәмлекләр:	Үзәкләр:
1. Коми Республикасы.	А. Екатеринбург шәһәре.
2. Свердловск өлкәсе.	Б. Сыктывкар шәһәре.
3. Ненец автономияле округы.	В. Улан-Удэ шәһәре.
4. Бурятия Республикасы.	Г. Нарьян-Мар шәһәре.

4. Мәсьәләне чишегез һәм дөрес җавапны сайлап алыгыз. Әгәр Иркутск шәһәрендә пояс вакыты 18 сәгать булса, Казан шәһәрендә пояс вакыты күпме булыр?

1. 8 сәгать.
2. 13 сәгать.
3. 15 сәгать.

5. Мәсьәләне чишегез һәм дөрес җавапны сайлап алыгыз. Әгәр Чита шәһәрендә (географик озынлыгы 113° 30′ кч. оз.) җирле вакыт 15 сәгать 32 минут булса, Калининград шәһәрендә (географик озынлыгы 20° 31′ кч.оз.) җирле вакыт күпме булыр?

1. 9 сәгать 20 минут 4 секунд.
2. 9 сәгать 52 минут 23 секунд.
3. 10 сәгать 31 минут 14 секунд.

4 нче вариант

1. Россия территориясенең өч климатик пояста урнашуы нәрсә белән аңлатыла?

1. Илнең төньяктан көньякка сузылышы белән.
2. Илнең көнбатыштан көнчыгышка сузылышы белән.

2. Бу дәүләтләрнең кайсылары Россия белән диңгез буенча чикләшә?

1. Төркия, Азәрбайҗан, Норвегия.
2. Таҗикстан, Кытай, Вьетнам.
3. Гыйрак, Бельгия, Югославия.

3. Административ-территориаль берәмлекләргә аларның үзәкләрен туры китереп җавап бирегез:

Административ-территориаль берәмлекләр:	Үзәкләр:
1. Чукот автономияле округы.	А. Грозный шәһәре.
2. Татарстан Республикасы.	Б. Анадырь шәһәре.
3. Чечен (Ичкерия) Республикасы.	В. Дудинка шәһәре.
4. Таймыр автономияле округы.	Г. Казан шәһәре.

4. Мәсьәләне чишегез һәм дөрес җавапны сайлап алыгыз. Әгәр Смоленск шәһәрендә пояс вакыты иртәнге 9 булса, Магадан шәһәрендә пояс вакыты күпме булыр?

1. 20 сәгать.
2. 15 сәгать.
3. 17 сәгать.

5. Мәсьәләне чишегез һәм дөрес җавапны сайлап алыгыз. Әгәр Владивосток шәһәрендә (географик озынлыгы $131^{\circ}55'$ кч. оз.) җирле вакыт 15 сәгать 18 минут 22 секунд күрсәтсә, Казанда (географик озынлыгы $49^{\circ}08'$ кч. оз.) җирле вакыт күпме булыр?

1. 10 сәгать 32 минут 11 секунд.
2. 9 сәгать 9 минут 14 секунд.
3. 21 сәгать 29 минут 30 секунд.

1 нче вариант

1. Бу диңгезләрнең кайсылары Атлантик океан бассейнына керә?

1. Карский, Лаптевлар, Чукот диңгезләре.
2. Кара, Балтыйк, Азов диңгезләре.
3. Беринг, Охота, Япон диңгезләре.

2. Җир шарында һәм Россиядә иң сай диңгез — ...

1. Ак диңгез.
2. Азов диңгезе.
3. Баренц диңгезе.

3. Океан төбенең кайсы өлешендә тирәнлек 0 м дан 200 м га кадәр була?

1. Материк сөзәклегендә.
2. Материк сайлыгында (шельф).
3. Улаксыман упкыннарда.

4. Бу океан диңгезләренә хас булган үзлекләр: шельфлы һәм аз тозлы диңгезләр, табигать шартлары кырыс. Болар — ...

1. Тын океан диңгезләре.
2. Атлантик океан диңгезләре.
3. Төньяк Боз океаны диңгезләре.

5. Россия территориясен юучы диңгезләр арасында мәйданы буенча иң зур (2315 мең кв. км) һәм тирән (уртача — 1640 м, максималь — 5500 м) диңгез — ...

1. Көнчыгыш Себер диңгезе.
2. Беринг диңгезе.
3. Охота диңгезе.

2 нче вариант

1. Бу диңгезләрнең кайсылары Төньяк Боз океаны бассейнына керә?

1. Балтыйк, Кара, Азов диңгезләре.
2. Каспий һәм Арал диңгезләре.
3. Ак, Баренц, Көнчыгыш Себер диңгезләре.

2. Россия территориясе яр буйларында иң биек су күтәрелеше кайсы култыкта күзәтелә?

1. Мезень култыгында.
2. Фин култыгында.
3. Пенжина култыгында.

3. Бу диңгезләргә аларның промысел балыкларын туры китереп җавап бирегез:

Диңгезләр:	Промысел балыклары:
1. Балтыйк.	А. Сельдь, камбала, сайра, сөләйман балыклары.
2. Япон.	Б. Осетр балыклары, судак, корбан балыгы, вобла.
3. Каспий.	В. Килька, салака, тәрәч, еланбалык.

4. Океан төбенең кайсы өлешендә тирәнлек 6000—7000 м дан да артыграк?

1. Материк сөзәклегендә.
2. Материк сайлыгында (шельф).
3. Улаксыман упкыннарда.

5. Россия чикләрендә мәйданы буенча иң зур утрау — ...

1. Врангель утравы.
2. Яңа Җир архипелагы.
3. Сахалин утравы.

3 нче вариант

1. Бу диңгезләрнең кайсылары эчке агышлы бассейнга керә?

1. Балтыйк, Кара, Азов диңгезләре.
2. Каспий һәм Арал диңгезләре.
3. Ак, Баренц, Көнчыгыш Себер диңгезләре.

2. Россиянең башка диңгезләреннән аерылмалы буларак, бу диңгез 150—200 м тирәнлектән алып төбенә кадәр агулы сероводород газы белән тулган. Бу — ...

1. Япон диңгезе.
2. Лаптевлар диңгезе.
3. Кара диңгез.

3. Түбәндә саналган диңгезләргә аларның промысел балыкларын туры китереп җавап бирегез:

Диңгезләр:	Промысел балыклары:
1. Баренц.	А. Осетр балыклары, скумбрия, ставрида.
2. Охота.	Б. Сельдь, камбала, сайра, сөләйман балыклары.
3. Азов.	В. Тәрәч, пикша, диңгез алабугасы.

4. Түбәндәге үзенчәлекләр кайсы океан диңгезләренә хас: тирән сулы диңгезләр, аларның кырыйларында вулканнар урнашкан, төпләрендә һәм яр буйларында җир тетрәүләр еш була һәм алар цунамилар китереп чыгара.

1. Тын океан диңгезләре.
2. Атлантик океан диңгезләре.
3. Төньяк Боз океаны диңгезләре.

5. Россия чикләрендә иң салкын һәм бозлы диңгез — ...

1. Көнчыгыш Себер диңгезе.
2. Чукот диңгезе.
3. Баренц диңгезе.

4 нче вариант

1. Бу диңгезләрнең кайсылары Тын океан бассейнына керә?

1. Карский, Лаптевлар, Чукот диңгезләре.
2. Кара, Балтыйк, Азов диңгезләре.
3. Беринг, Охота, Япон диңгезләре.

2. Кайсы диңгезләр моннан 25 млн еллар элек булган Тетис океаны бассейнына кергәннәр?

1. Каспий, Кара, Азов диңгезләре.
2. Балтыйк, Кара, Азов диңгезләре.

3. Су чигенеше — ...

1. Океан һәм диңгезләрдә вакыты белән суның периодик рәвештә күтәрелүе.
2. Океан һәм диңгезләрдә вакыты белән суның периодик рәвештә төшүе.

4. Кайсы бугаз ике диңгезне һәм океанны тоташтыра, ә ике материкны һәм дәүләтләрне аера?

1. Беринг бугазы.
2. Босфор бугазы.
3. Татар бугазы.

5. Россия чикләрендә иң җылы диңгез — ...

1. Япон диңгезе.
2. Кара диңгез.
3. Балтыйк диңгезе.

РОССИЯ ТЕРРИТОРИЯСЕНЕҢ РЕЛЬЕФЫ, ГЕОЛОГИК ТӨЗЕЛЕШЕ ҺӘМ ФАЙДАЛЫ КАЗЫЛМАЛАРЫ

1 нче вариант

1. Россия территориясендә нинди рельеф формалары өстенлек итә?

1. Таулы рельеф формалары.
2. Тигезлекле рельеф формалары.

2. Тигезлекле рельеф формалары өстенлек иткән өлкәләр нигезендә нинди геологик структуралар ята?

1. Платформалар.
2. Җыерчыклану өлкәләре.

3. Кристаллик калкан — ...

1. Платформаның нигезендә утырма каплам урнашкан участоклар.
2. Платформаның кристаллик нигезе өскә чыккан киң участоклар.

4. Каледон тау ясалуының төп фазасы кайсы чорда барган?

1. Кайнозой эрасының неоген чорында.
2. Мезозой эрасының юра чорында.
3. Палеозой эрасының силур чорында.

5. Алтай тауларының көнбатыш өлеше кайсы тау ясалу чорында барлыкка килгән?

1. Мезозой.
2. Герцин.
3. Каледон.

6. Өстенлек итүче абсолют биеклеге буенча Ока-Дон тигезлеге — ...

1. Түбәнлек.
2. Калкулык.
3. Яссы таулык.

7. Иң биек тау түбәсенә тиешле рельеф формасын туры китереп әйтегез:

Рельеф формалары:	Тау түбәләре:
1. Урал таулары.	А. Таш (Камень) түбәсе.
2. Алтай.	Б. Халык (Народная) түбәсе.
3. Путорана платосы.	В. Җиңү (Победа) пигы.
4. Черский тау сырты.	Г. Белуха түбәсе.

8. Экзоген процессларга алар барлыкка китергән кече рельеф формаларын туры китереп җавап бирегез:

Экзоген процесслар:	Кече рельеф формалары:
1. Бозлык эшчәнлеге.	А. Елга үзәне.
2. Җил эшчәнлеге.	Б. Дюна.
3. Агым суларның эшчәнлеге.	В. Морена түбәнлекләре (калкулыклары).

9. Файдалы казылмаларның төрләренә алар таралган районнарны туры китереп җавап бирегез:

Файдалы казылмалар:	Таралу районнары:
1. Газ.	А. Якутия (Саха).
2. Ташкүмер.	Б. Көнбатыш Себернең төньяк өлеше.
3. Алмаз.	В. Тунгуска бассейны.

10. Үткән геологик чорларда җирдә яшәгән хайван һәм үсемлекләрнең казылма калдыкларын өйрәнә торган фән — ...

1. Геохронология.
2. Геотектоника.
3. Палеонтология.

2 нче вариант

1. Россия территориясе өслегенең күпчелек өлеше кайсы якка таба авыш?

1. Төньякка.
2. Көньякка.

2. Таулы рельеф формалары өстенлек иткән өлкәләр нигезендә нинди геологик структуралар ята?

1. Платформалар.
2. Җыерчыклану өлкәләре.

3. Россия территориясендә сүнгән һәм ата торган вулканнарның күп санлы конуслары кайсы регионда күзәтелә?

1. Камчаткада.
2. Кавказда.
3. Алтайда.

4. Альп тау ясалу эпохасының төп фазасы кайсы чорда барган?

1. Кайнозой эрасының неоген чорында.
2. Мезозой эрасының юра чорында.
3. Палеозой эрасының силур чорында.

5. Төньяк-Көнчыгыш Себер таулары кайсы тау ясалу эпохасында барлыкка килгәннәр?

1. Мезозой.
2. Герцин.
3. Каледон.

6. Өстенлек итүче абсолют биеклеге буенча Төньяк Уваллар — ...

1. Түбәнлек.
2. Калкулык.
3. Яссы таулык.

7. Иң биек тау түбәсенә үзенең рельеф формасын туры китереп җавап бирегез:

Рельеф формалары:	Тау түбәләре:
1. Тянь-Шань.	А. Мунку-Сардык түбәсе.
2. Памир.	Б. Җиңү пигы.
3. Кавказ.	В. Коммунизм пигы.
4. Саяннар.	Г. Эльбрус түбәсе.

8. Экзоген процессларга алар барлыкка китергән кече рельеф формаларын туры китереп җавап бирегез:

Экзоген процесслар:	Рельеф формалары:
1. Тайга-тундлык.	А. Барханнар.
2. Агым суларның эшчәнлеге.	Б. Ерымнар, коры елга үзәннәре.
3. Җилнең эшчәнлеге.	В. Булгунняхлар.

9. Файдалы казылмаларның төрләренә алар таралган районнарны туры китереп җавап бирегез:

Файдалы казылмалар:	Таралу районнары:
1. Нефть.	А. Мәскәү яны бассейны.
2. Көрән күмер.	Б. Хибин таулары.
3. Апатитлар.	В. Печора бассейны.

10. Җир өслеге рельефы үзенчәлекләре нинди картада күрсәтелә?

1. Физик картада.
2. Геологик картада.
3. Тектоник картада.

3 нче вариант

1. Россиядә таулар көньяк-көнбатышта, көньякта һәм көнчыгышта урнашкан, чөнки бу территория ...

1. Литосфера плиталарының чигендә урнашкан.
2. Җир кабыгының төрле типлары тоташкан урында ята.

2. Эндоген (эчке) рельеф ясалу процесслары нинди рельеф формаларын барлыкка китерә?

1. Эре рельеф формаларын.
2. Вак рельеф формаларын.

3. Рәсемдә нинди платформа күрсәтелгән?

1. Борынгы (протерозой эрасында барлыкка килгән) платформа.
2. Яшь (палеозой эрасында барлыкка килгән) платформа.



Рис. 1

4. Герцин тау ясалу эпохасының төп фазасы кайсы чорда барган?

1. Кайнозой эрасының дүртенчел чорында.
2. Мезозой эрасының триас чорында.
3. Палеозой эрасының ташкүмер чорында.

5. Геологик эраларга алардагы тереклек үсеше этапларын туры китереп җавап бирегез:

Геологик эра:	Җир шарында тереклек үсешенең этаплары:
1. Кайнозой (неоген чоры).	А. Беренче җир өсте хайваннары барлыкка килә.
2. Мезозой (триас чоры).	Б. Имезүчеләр барлыкка килә.
3. Палеозой (ордовик чоры).	В. Кешесыман маймыллар барлыкка килә.

6. Өстенлек итүче абсолют биеклеге буенча Лена буе платосы — ...

1. Түбәнлек.
2. Калкулык.
3. Яссы таулык.

7. Россия территориясендә абсолют биеклеге буенча иң түбән нокталар кайсы регионда урнашкан?

1. Көнбатыш Себер тигезлегендә.
2. Колыма түбәнлегендә.
3. Каспий буе түбәнлегендә.

8. Валдай калкулыгының хәзерге рельефы ясалу нәрсә белән бәйле?

1. Җил эшчәнлеге.
2. Борынгы бозланыш.
3. Күпьеллык туңлык.

9. Файдалы казылмаларның төрләрен алар таралган районнарга туры китереп җавап бирегез:

Файдалы казылмалар:	Таралу районнары:
1. Нефть.	А. КМА.
2. Тимер рудасы.	Б. Ерак Көнчыгыш.
3. Аккургаш рудалары.	В. Төньяк Кавказ.

10. Җир кабыгы тау токымнарының барлыкка килү вакытларын, төп геологик вакыйгаларны өйрәнүче фән — ...

1. Геохронология.
2. Геотектоника.
3. Палеонтология.

4 нче вариант

1. Россия территориясендә төрле рельеф формалары таралуның сәбәбе — ...

1. Тектоник структураларның төрлелеге.
2. Тау токымнарының геологик яше төрлелеге.

2. Экзоген рельеф ясалу процесслары нинди рельеф формаларын барлыкка китерә?

1. Эре рельеф.
2. Кече рельеф.

3. Россия территориясенең төньяк һәм төньяк-көнбатышының зур өлешен каплап алган кат-кат бозлану кайсы чорда күзәтелгән?

1. Кайнозой эрасының дүртенчел чорында.
2. Мезозой эрасының триас чорында.
3. Палеозой эрасының ташкүмер чорында.

4. Рәсемдә нинди платформа күрсәтелгән?

1. Борынгы (протерозой эрасында барлыкка килгән) платформа.
2. Яшь (палеозой эрасында барлыкка килгән) платформа.



Рәс. 2

5. Геологик эраларга алардагы тереклек үсеше этапларын туры китереп әйтегез:

Геологик эра:	Җир шарында тереклек үсеше этаплары:
1. Кайнозой.	А. Бик гади бер күзәнәкле бактерияләр чоры.
2. Мезозой.	Б. Җир өсте үсемлекләре килеп чыга.
3. Палеозой.	В. Ачык орлыклы үсемлекләр өстенлек итә.
4. Архей.	Г. Ябык орлыклы үсемлекләр өстенлек итә.

6. Өстенлек итүче абсолют биеклеге буенча Көнбатыш Себер тигезлеге — ...

1. Түбәнлек.
2. Калкулык.
3. Яссы таулык.

7. Россиянең иң биек тау түбәсе кайсы тау системасында урнашкан?

1. Кавказ тауларында.
2. Алтай тау илендә.
3. Сихотэ-Алинь тау илендә.

8. Якутиянең хәзерге рельефы ясалу нәрсә белән бәйле?

1. Җил эшчәнлеге.
2. Борынгы бозланыш.
3. Күпьеллык туңлык.

9. Файдалы казылмаларның төрләренә алар таралган районнарны туры китереп җавап бирегез:

Файдалы казылмалар:

1. Ташкүмер.
2. Төсле металл рудалары.
3. Газ.

Таралу районнары:

А. Урал таулары.
Б. Кузбасс.
В. Идел-Урал бассейны.

10. Нинди картада утырма тау токымнарының барлыкка килү вакыты һәм аларның составы күрсәтелә?

1. Физик картада.
2. Геологик картада.
3. Тектоник картада.

1 нче вариант

1. Россия территориясенең зур өлеше кайсы климатик пояста урнашкан?

1. Арктик.
2. Субарктик.
3. Уртача.
4. Субтропик.

2. Рәсемдә нинди атмосфера фронты күрсәтелгән?

1. Салкын фронт.
2. Җылы фронт.



Рәс. 3

3. Изобаралар — ...

1. Уртача температуралары бертөрле булган урыннарны картада тоташтыручы сызыклар.
2. Билгеле бер вакытта еллык явым-төшемнәре тигез булган урыннарны картада тоташтыручы сызыклар.
3. Атмосфера басымы бер үк дәрәҗәдә булган урыннарны картада тоташтыручы сызыклар.

4. Антициклонга нинди һава торышы хас?

1. Болытлы һәм яңгырлы.
2. Коры һәм кояшлы.

5. Кояш радиациясе җир өслегенең нинди өлешеннән күбрәк кайтарыла?

1. Урманнар өстеннән.
2. Комнар өстеннән.
3. Кар өстеннән.

6. Климатның бу төренә түбәндәге үзенчәлекләр хас: ел эчендә континенталь УҺМ өстенлек итә, ә кыш көне континенталь АҺМ нык тәэсир ясый: һаваның еллык, сезонлык һәм тәүлеклек температурасының аермасы бик нык үзгәрә, еллык явым-төшем күләме 200—400 мм; аз карлы бик салкын кышлар һәм уртача җылы җәй. Бу — ...

1. Континенталь климат.
2. Кискен континенталь климат.
3. Муссонлы климат.

7. Кола ярымутравына нинди климат төре хас?

1. Арктик.
2. Субарктик.
3. Уртача континенталь УКП.

8. Россия территориясендә һаваның иң югары температурасы кайсы районда күзәтелә?

1. Кавказның Кара диңгез яр буенда (Сочи шәһәре).
2. Түбән Идел буенда (Эльтон һәм Баскунчак күлләре янында).
3. Калмык Республикасында (Нарын-Худук авылында).

9. Бик озак коры һәм эссе һава торышы нәтиҗәсендә барлыкка килгән корылык нинди һава массаларына бәйле?

1. Тропик диңгез.
2. Континенталь тропик.
3. Уртача диңгез.

10. Һава торышын билгеле бер вакытка фаразлау өчен кулланыла торган картаның исемен атагыз.

1. Климатик карта.
2. Синоптик карта.
3. Изотермалар картасы.

2 нче вариант

1. Россия территориясендә климатның континентальлеге кайсы юнәлештә көчәя?

1. Көнбатыштан көнчыгышка таба.
2. Төньяктан көньякка таба.

2. Рәсемдә нинди атмосфера өермәсе күрсәтелгән?

1. Циклон.
2. Антициклон.



Рәс. 4

3. Изогиеталар — ...

1. Уртача температуралары бертөрле булган урыннарны картада тоташтыручы сызыклар.
2. Билгеле бер вакытта еллык явым-төшемнәре тигез булган урыннарны картада тоташтыручы сызыклар.
3. Атмосфера басымы бер үк дәрәҗәдә булган урыннарны картада тоташтыручы сызыклар.

4. Җылы фронт узганда һава торышы ничек үзгәрә?

1. Озак һәм дәвамлы яңгырлар ява.
2. Кыска вакытлы коеп яуган яшенле яңгырлар күзәтелә, яңгырдан соң тиз аяза һәм кояшлы, аяз көннәр башлана.

5. Россия территориясендә кояш радиациясенең иң аз күләме кайсы районда күзәтелә?

1. Кавказның Кара диңгез яр буенда.
2. Уртача киңлекләрдә (урман зонасы).
3. Төньяк Арктикада.

6. Климатның кайсы төренә түбәндәге үзенчәлекләр хас: кыш көне — коры һәм салкын континенталь ҺМ, ә җәй көне — җылы һәм дымлы диңгез ҺМ; уртача һава температурасы $t_г = -24$ °C, -16 °C, ә $t_и = +16$ °C, $+20$ °C, еллык явым-төшем күләме 600—800 мм һәм аның иң күп күләме җәй көне күзәтелә, сезонлы җилләрнең тәэсире зур. Бу — ...

1. Континенталь УКП.
2. Кискен континенталь УКП.
3. Муссонлы УКП.

7. Каспий буе түбәнлегенә нинди климат төре хас?

1. Субарктик.
2. Уртача континенталь УКП.
3. Континенталь УКП.

8. Россия территориясендә иң көчле җилләр (тизлеге 67—69 м/с яки 240—250 км/сәг) кайсы районда күзәтелә?

1. Яңа Җир архипелагында.
2. Төньяк Кавказда.
3. Ладога күлендә.

9. Көчле циклоннар түбәндәге табигать күренешләренең кайсын китереп чыгаруда төп сәбәп булып тора?

1. Давыллар.
2. Ком бураннары.
3. Корылык.

10. Күпьеллык күзәтүләр нигезендә төзелгән һәм территориянең климат үзенчәлекләрен сурәтләүче картаның исемен атагыз.

1. Климатик карта.
2. Синоптик карта.
3. Изотермалар картасы.

3 нче вариант

1. Россия климатына кайсы океан иң зур тәэсир ясый?

1. Тын океан.
2. Атлантик океан.
3. Һинд океаны.

2. Рәсемдә нинди атмосфера фронты күрсәтелгән?

1. Салкын фронт.
2. Җылы фронт.

Рәс. 5

3. Изотермалар — ...

1. Уртача температуралары бертөрле булган урыннарны картада тоташтыручы сызыклар.
2. Билгеле бер вакытта еллык явым-төшеме тигез булган урыннарны картада тоташтыручы сызыклар.
3. Атмосфера басымы бер үк дәрәҗәдә булган урыннарны картада тоташтыручы сызыклар.

4. Циклонга нинди һава торышы хас?

1. Болытлы һәм яңгырлы.
2. Коры һәм кояшлы.

5. Кояш радиациясе Җир өслегенең нинди өлешләреннән иң аз кайтарыла?

1. Урман өстеннән.
2. Комлыклар өстеннән.
3. Кар өстеннән.

6. Бу климат төренә түбәндәге үзенчәлекләр хас: бу климат, нигездә, көнбатыш күчерү йогынтысына бәйләнгән Атлантиканың уртача, кыш көне чагыштырмача җылы, ә җәй көне салкынча, ләкин һәрвакыт дымлы ҺМ нәтиҗәсендә барлыкка килә: уртача һава температурасы $t_г = -8\ ^\circ C, -12\ ^\circ C$, $t_ц = +16\ ^\circ C, +24\ ^\circ C$, еллык явым-төшем күләме 500—800 мм. Бу — ...

1. Субарктик климат.
2. Уртача континенталь УКП.
3. Континенталь УКП.

7. Урта Себер яссы таулыгының зур өлешенә нинди климат төре хас?

1. Уртача континенталь УКП.
2. Континенталь УКП.
3. Кискен континенталь УКП.

8. Россия территориясендә һаваның иң түбән температурасы кайсы районда күзәтелә?

1. Байкал аръягында (Чита шәһәре).
2. Якутия (Саха) Республикасында (Верхоянск шәһәре).
3. Якутия (Саха) Республикасында (Оймякон шәһәре).

9. Арктик һәм уртача һава массаларын аера торган климатик фронтның исемен атагыз:

1. Поляр фронт.
2. Арктик фронт.
3. Тропик фронт.

10. Түбәндә саналган табигый зоналарның кайсында дымлылык җитәрлек түгел?

1. Ярымчүлләр зонасында.
2. Далалар зонасында.
3. Тундра зонасында.

4 нче вариант

1. Кояш радиациясенең күләме нәрсәгә бәйле?

1. Явым-төшем күләменә.
2. Кояш нурларының Җиргә төшү почмагына.

2. Рәсемдә кайсы атмосфера өермәсе күрсәтелгән?

1. Циклон.
2. Антициклон.



Рәс. 6

3. Россия территориясендә һава массаларының күчүенә (хәрәкәт итүенә) күбесенчә нинди җилләр тәэсир итә?

1. Төньяк-көнчыгыш җилләр.
2. Көнбатыш җилләр.
3. Муссоннар.

4. Салкын фронт узганда һава торышы ничек үзгәрә?

1. Озак һәм дәвамлы яңгырлар ява.
2. Кыска вакытлы коеп яуган яшенле яңгырлар күзәтелә, яңгырдан соң тиз аяза һәм кояшлы, аяз көннәр башлана.

5. Россия территориясендә кояш радиациясенең иң аз күләме кайсы районга туры килә?

1. Кавказның Кара диңгез яр буе.
2. Уртача киңлекләр (урман зонасы).
3. Төньяк Арктика.

6. Бу климат төренә түбәндәге үзенчәлекләр хас: кыш көне — АҺМ, ә җәй көне — УҺМ, кыш озын һәм кырыс (уртача $t_{г}$ = −24 °С, −32 °С), бигрәк тә климатның кырыслыгы көнбатыштан көнчыгышка киткән саен көчәя, ә җәй айлары кыска һәм салкынча (уртача $t_{и}$ = +4 °С, +12 °С), уртача еллык явым-төшем күләме 200—400 мм, артык дымлану хас. Бу — ...

1. Субарктик.
2. Уртача континенталь УКП.
3. Кискен континенталь УКП.

7. Ямал ярымутравының үзәк һәм көньяк өлешләренә нинди климат төре хас?

1. Субарктик.
2. Континенталь УКП.
3. Кискен континенталь УКП.

8. Россия территориясендә иң җылы кыш кайсы районда күзәтелә?

1. Кавказның Кара диңгез яр буенда (Сочи шәһәре).
2. Түбән Идел буенда (Эльтон һәм Баскунчак күлләре янында).
3. Калмык Республикасында (Нарын-Худук авылында).

9. Уртача һәм тропик һава массаларын аера торган климатик фронт ничек атала?

1. Поляр фронт.
2. Арктик фронт.
3. Тропик фронт.

10. Түбәндә күрсәтелгән табигый зоналарның кайсына артык дымлану хас?

1. Ярымчүлләр зонасына.
2. Далалар зонасына.
3. Тундра зонасына.

1 нче вариант

1. Россия территориясендә эчке суларның зур өлеше кайсы океан бассейнына керә?

1. Тын океан.
2. Атлантик океан.
3. Һинд океаны.
4. Төньяк Боз океаны.

2. Идел, Урал, Терек, Сулак елгалары кайсы океан бассейнына керә?

1. Тын океан бассейнына.
2. Атлантик океан бассейнына.
3. Төньяк Боз океаны бассейнына.
4. Эчке агымсулы бассейнга.

3. Әгәр елганың авышлыгы 1 км га 10 см булса, бу елга — ...

1. Тигезлек елгасы.
2. Тау елгасы.

4. Су режимы буенча кайсы елга язгы ташулы елгалар төркеменә керә?

1. Днепр.
2. Кубань.
3. Уссури.

5. Кайсы елга нигездә кар сулары белән туена?

1. Зөя.
2. Идел.
3. Аму-Дәрья.

6. **Россия территориясендә иң тулы сулы елга — ...**

1. Обь елгасы.
2. Енисей елгасы.
3. Лена елгасы.

7. **Казанлыгы ничек барлыкка килүгә карап, Байкал күле нинди типтагы күлләр төркеменә керә?**

1. Вулканик.
2. Тектоник.
3. Бозлану.

8. **Су басуларга каршы иң яхшы чара — ...**

1. Урманнарны кисеп бетерү.
2. Елга агымын тәртипкә салу.

9. **Россия территориясендә мәйданы буенча иң зур сазлыклар кайда урнашкан?**

1. Көнчыгыш Европа тигезлегендә.
2. Көнбатыш Себер тигезлегендә.
3. Урта Себер яссы таулыгында.

10. **А. С. Пушкинның шигъри юллары кайсы елга турында сөйли:**

... всю ночь
Рвалася к морю против бури,
Не одолев их буйной дури ...
И спорить стало ей невмочь ...
Поутру над ее брегами
Теснился кучами народ,
Любуясь брызгами, горами
И пеной разъяренных вод.
Но силой ветра от залива
Перегражденная ...
Обратно шла, гневна, бурлива,
И затопляла острова,
Погода пуще свирепела,
... вздувалась и ревела,
Котлом клокоча и клубясь,
И вдруг, как зверь остервенясь,
На город кинулась.

1. Идел (Волга). 2. Днепр. 3. Нева.

2 нче вариант

1. Россия территориясе елгаларының күбрәк өлешенә нинди су режимы хас?

1. Язгы ташулы.
2. Җәйге ташулы.
3. Су арту режимлы.

2. Анадырь, Охота, Амур, Камчатка елгалары кайсы океан бассейнына керә?

1. Тын океан бассейнына.
2. Атлантик океан бассейнына.
3. Төньяк Боз океаны бассейнына.
4. Эчке агымсулы бассейнга.

3. Әгәр елганың агым тизлеге зур булса, бу елга — ...

1. Тау елгасы.
2. Тигезлек елгасы.

4. Кайсы елга су арту режимлы елгалар төркеменә керә?

1. Печора. 2. Терек. 3. Амур.

5. Кайсы елга күбрәк бозлык сулары белән туена?

1. Днепр.
2. Кубань.
3. Уссури.

6. Россия территориясендә елга бассейнының мәйданы иң зур булган елга — ...

1. Обь.
2. Енисей.
3. Лена.

7. Казанлыгы барлыкка килүгә карап, Ладога күле нинди типтагы күлләр төркеменә керә?

1. Вулканик.
2. Тектоник.
3. Бозлану.

8. Россия территориясендә иң зур мәйданлы бозлыклар кайда урнашкан?

1. Кавказ тауларында.
2. Алтай тау илендә.
2. Төньяк-Көнчыгыш Себер тауларында.

9. Елгада кинәт су күтәрелү — ул ...

1. Суның билгеле бер вакытта ташуы.
2. Су ташкыны.

10. А. С. Пушкинның шигъри юллары кайсы елга турында сөйли:

Блеща средь полей широких
Вот он льется !... Здравствуй, ...!
От сынов твоих далеких
Я привез тебе поклон.

Как прославленного брата,
Реки знают тихий ...;
От Аракса и Евфрата
Я привез тебе поклон.

Отдохнув от злой погони,
Чуя родину свою,
Пьют уже ... кони
Арпачайскую струю.

Приготовь же, ... заветный,
Для наездников лихих
Сок кипучий, искрометный
Виноградников твоих.

1. Терек. 2. Дон. 3. Урал.

3 нче вариант

1. Россия территориясе елгаларының күбрәк өлеше Төньяк Боз океаны бассейнына керү нәрсә белән аңлатыла?

1. Рельеф үзенчәлекләре белән.
2. Климат үзенчәлекләре белән.
3. Табигый зоналарның урнашу үзенчәлекләре белән.

2. Нева, Көнбатыш Двина, Днепр, Дон, Кубань елгалары кайсы океан бассейнына керә?

1. Тын океан бассейнына.
2. Атлантик океан бассейнына.
3. Төньяк Боз океаны бассейнына.
4. Эчке агымсулы бассейнга.

3. Әгәр елганың авышлыгы 1 км га 3 см булса, бу елга — ...

1. Тигезлек елгасы.
2. Тау елгасы.

4. Су режимы буенча кайсы елга җәйге ташулы елгалар төркеменә керә?

1. Печора. 2. Хатанга. 3. Амур.

5. Кайсы елга күбрәк яңгыр сулары белән туена?

1. Уссури.
2. Төньяк Двина.
3. Колыма.

6. Россия территориясендә иң озын елга — ...

1. Енисей.
2. Лена.
3. Идел.

7. Казанлыклары барлыкка килүгә карап, Камчатка ярымутравындагы күлләр нинди типтагы күлләр төркеменә керә?

1. Вулканик.
2. Тектоник.
3. Бозлану.

8. Россия территориясендә һәм Җир шарында иң тирән күл — ...

1. Алтынкүл.
2. Каспий диңгезе.
3. Байкал күле.

9. Россия территориясендә иң зур мәйданлы мәңгелек туңлык кайсы районда күзәтелә?

1. Европа өлешендә.
2. Көнбатыш Себердә.
3. Көнчыгыш Себердә.

10. М. Ю. Лермонтовның шигъри юллары кайсы елга турында сөйли:

... воет, дик и злобен,
Меж утесистых громад.
Буре плач его подобен,
Слезы брызгами летят.
Но, по степи разбегаясь,
Он лукавый принял вид
И, приветливо ласкаясь,
Морю Каспию журчит...

1. Терек. 2. Дон. 3. Урал.

4 нче вариант

1. Россия территориясендәге елгаларның күпчелеге катнаш юл белән туена. Кайсы сулар бу елгаларны туендыруда өстенлек итә?

1. Кар сулары.
2. Яңгыр сулары.
3. Бозлык сулары.

2. Яна, Индигирка, Колыма, Печора елгалары кайсы океан бассейнына керә?

1. Тын океан бассейнына.
2. Атлантик океан бассейнына.
3. Төньяк Боз океаны бассейнына.
4. Эчке агымсулы бассейнга.

3. Кайсы елга каты матдәләрне иң күп күләмдә күчерә?

1. Идел.
2. Терек.
3. Амур.

4. Су режимы буенча кайсы елга язгы ташулы елгалар төркеменә керә?

1. Камчатка.
2. Шилка.
3. Обь.

5. Кайсы елга күбрәк яңгыр сулары белән туена?

1. Зөя.
2. Идел.
3. Аму-Дәрья.

6. Яна елгасында су ташу җәй көне була, чөнки ...

1. Муссонлы яңгырлар ява.
2. Кар эри.
3. Тауларда бозлыклар эри.

7. Россия территориясендә һәм Җир шарында мәйданы буенча иң зур күл — ...

1. Алтынкүл.
2. Каспий диңгезе.
3. Байкал күле.

8. Тектоник күлләргә нинди үзенчәлекләр хас?

1. Казанлыклары түгәрәк формада.
2. Бик тирән булмаган, ләкин нык телгәләнгән казанлыклар.
3. Яр буйлары текә һәм бик тирән.

9. Елга суының ел әйләнәсендә билгеле бер вакытта күтәрелү күренеше — ...

1. Су ташу.
2. Су күтәрелеше (ташкыны).

10. Н. А. Некрасовның шигъри юллары кайсы елга турында сөйли:

О ..., после многих лет
Я вновь принес тебе привет.
Уж я не тот, но ты светла
И величава, как была.
Кругом все та же даль и ширь,
Все тот же виден монастырь
На острову, среди песков,
И даже трепет прежних дней
Я ощутил в душе моей,
Заслыша звон колоколов.

* * *

О ...! ... колыбель моя!
Любил ли кто тебя, как я?
Один, по утренним зарям,
Когда еще все в мире спит
И алый блеск едва скользит
По темно-голубым волнам,
Я убегал к родной реке.

* * *

Тогда я думать был готов,
Что ни уйду я никогда
С песчаных этих берегов.

1. Идел (Волга). 2. Днепр. 3. Нева.

1 нче вариант

1. Нинди туфраклар барлыкка килүгә балчыклы грунт сәбәп була?

1. Тиз юылучы туфраклар.
2. Начар юылучы сазлыклы һәм тозлы туфраклар.

2. Төрле туфракларның уңдырышлылыгын билгели торган төп горизонтны атагыз.

1. Черемә-аккумулятив (гумус) горизонты.
2. Элювий (юылып төшү) горизонты.
3. Иллювий (юылган тозларны сеңдерү) горизонты.
4. Туфракны барлыкка китерүче тау токымы (ана токым).

3. Туфракның уңдырышлылыгын билгели торган иң яхшы структуралы туфрак — ...

1. Кантарлы оешкан.
2. Чикләвексыман-төерле.
3. Төерле-бөртекле.

4. Туфракның бу төренә түбәндәге үзенчәлекләр хас: борынгы бозланыш чоры үткәч барлыкка килгән, суда эрегән матдәләр туфракның аскы горизонтына үтеп керә, элювиаль горизонты ачык, аксыл төстә. Бу — ...

1. Көлсу туфрак.
2. Соры-урман туфрагы.
3. Кара туфрак.

5. Туфрак төренә туры килүче табигый зонаны билгеләгез:

Туфрак төре:	Табигый зона:
1. Аллювиаль.	А. Дала.
2. Тозлыклар.	Б. Елга үзәне (азональ зона).
3. Кара туфрак.	В. Ярымчүлләр һәм чүлләр.

2 нче вариант

1. Әгәр туфракның составында 20% балчык һәм 80% ком булса, механик составы буенча ул — ...

1. Балчыклы туфрак.
2. Балчыксыл туфрак.
3. Комсыл туфрак.
4. Комлы туфрак.

2. Туфракның механик составын һәм теге яки бу төре формалашуын билгели торган горизонт — ...

1. Черемә-аккумулятив (гумус) горизонты.
2. Элювий (юылып төшү) горизонты.
3. Иллювий (юылган тозларны сеңдерү) горизонты.
4. Туфракны барлыкка китерүче тау токымы (ана токым).

3. Тузансыман туфрак — ...

1. Структуралы.
2. Структурасыз.

4. Туфракның бу төре башка төрләр арасында иң уңдырышлы туфрак дип санала һәм дөньядагы бу төр туфракның 45% чамасы Россия территориясенә туры килә. Бу — ...

1. Көлсу туфрак.
2. Соры-урман туфрагы.
3. Кара туфрак.

5. Туфрак төренә туры килүче табигый зонаны билгеләгез:

Туфрак төре:	Табигый зона:
1. Көлсу туфрак.	А. Киң яфраклы урман.
2. Кәсле-көлсу туфрак.	Б. Катнаш урман.
3. Соры-урман туфрагы.	В. Ылыслы урман.

3 нче вариант

1. Нинди туфраклар барлыкка килүгә комлы һәм комсыз грунт сәбәп була?

1. Тиз юылучы туфраклар.
2. Начар юылучы сазлыклы һәм тозлы туфраклар.

2. Гумуслы органик матдәләрнең туплануы акрынлап кимү, туфракта беренчел минераллар таркалу һәм карбонатлар (сода) арту күзәтелә торган горизонт — ...

1. Черемә-аккумулятив (гумус) горизонты.
2. Элювий (юылып төшү) горизонты.
3. Иллювий (юылган тозларны сеңдерү) горизонты.
4. Туфракны барлыкка китерүче тау токымы (ана токым).

3. Россия территориясе мәйданының иң зур өлешен нинди туфрак төре алып тора?

1. Көлсу туфрак.
2. Соры-урман туфрагы.
3. Кара туфрак.

4. Бу төр туфраклар зур елга үзәне тугайларында очрый һәм, елга китермәләре белән чиратлашуы аркасында, «катламлы бәлеш» төзелеше белән аерылып тора. Бу — ...

1. Аллювиаль туфрак.
2. Тозлаклар.
3. Кара туфрак.

5. Туфрак төренә туры килүче табигый зонаны билгеләгез:

Туфрак төре:	Табигый зона:
1. Кызыл туфрак.	А. Катнаш урманнар.
2. Көрән-урман туфрагы.	Б. Дымлы субтропик урманнар.
3. Кәсле-көлсу туфрак.	В. Киң яфраклы урманнар.

4 нче вариант

1. Әгәр туфракның составында 70% балчык һәм 30% ком булса, механик составы буенча бу — ...

1. Балчыклы туфрак.
2. Балчыксыл туфрак.
3. Комсыл туфрак.
4. Комлы туфрак.

2. Туфраклар арасында кайсының гумус горизонты иң юка?

1. Кара туфракның.
2. Кәсле-көлсу туфракның.
3. Тундра-глей туфракларның.

3. Дала районнарында нинди туфрак эрозиясе күбрәк күзәтелә?

1. Су эрозиясе.
2. Җил эрозиясе.

4. Бу төр туфрак барлыкка килү процесслары акрын бара, туфрак профиле ярлы, аларның формалашуына күпьеллык туңлык көче йогынты ясый. Бу — ...

1. Арктик туфрак.
2. Кәсле-көлсу туфрак.
3. Тайга-туңлык туфраклары.

5. Туфрак төренә туры килүче табигый зонаны билгеләгез:

Туфрак төре:	Табигый зона:
1. Тайга-туңлык туфраклары.	А. Коры далалар һәм ярымчүлләр.
2. Сары туфрак.	Б. Ылыслы урманнар.
3. Каштан туфрак.	В. Дымлы субтропик урманнар.

1 нче вариант

1. Бу табигый зона Россия территориясендәге Рус тигезлегенең иң көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Ул — ...

1. Субтропиклар зонасы.
2. Ярымчүлләр һәм чүлләр зонасы.
3. Муссонлы катнаш урманнар зонасы.

2. Нинди табигый зонага түбәндәге үзенчәлекләр хас: субарктик климат өстенлек итә, июльнең уртача температурасы +8° С, + 10°С, гыйнварның –32°С, еллык явымтөшем күләме 200—400 мм?

1. Арктик чүлләр зонасына.
2. Тундра зонасына.
3. Катнаш урманнар зонасына.

3. Дымлы субтропик урманнар зонасына нинди туфрак төре хас?

1. Сары һәм кызыл туфраклар.
2. Кәсле-көлсу туфрак.
3. Каштан туфрак.

4. Тайга зонасының ылыслы агачлары (чыршы һәм нарат) Россия территориясенең кайсы өлешендә өстенлек итә?

1. Көнчыгыш Европа тигезлегендә.
2. Көнчыгыш Себердә.

5. Тундрада яшәүче җирле халыкның төп һөнәре — ...

1. Җир эшкәртү һәм аучылык.
2. Аучылык һәм болан асрау.

2 нче вариант

1. Кайсы табигый зона Россия территориясенең $^1/_8$ өлешендә өстенлек итә һәм Төньяк Боз океанында урнашкан утрауларны, материкның көньяк яр буйларын били, ә кайбер урыннарда Төньяк поляр түгәрәккә кадәр сузыла?

1. Арктик чүлләр зонасы.
2. Тундра зонасы.

2. Бу зонага түбәндәге үзенчәлекләр хас: зур өлешендә уртача континенталь климат өстенлек итә, гыйнварның уртача температурасы 0°С, ә июльнеке +20°С тан артыграк, явым-төшем күләме 200—400 мм, дымлылык коэффициенты берәмлектән кечерәк, кызу җилләр исә һәм корылык булырга мөмкин. Бу — ...

1. Яфраклы урман зонасы.
2. Далалар зонасы.

3. Чүлләр зонасына нинди туфрак төре хас?

1. Кара туфрак.
2. Каштан туфрак.
3. Көрән ярымчүлләр туфрагы.

4. Тайга зонасында нинди хайваннар яши?

1. Тиен, ак куян, пошы, соры аю, бүре, төлке, кеш һ. б.
2. Тюлень, морж, ак аю, диңгез кошлары.

5. Тундра җирләре кеше эшчәнлегендә нәрсә сыйфатында файдаланыла?

1. Көтүлекләр.
2. Чәчүлекләр.

3 нче вариант

1. Кавказның Кара диңгез яр буйларында нинди табигый зона өстенлек итә?

1. Субтропиклар.
2. Ярымчүлләр һәм чүлләр.
3. Муссонлы катнаш урманнар.

2. Кайсы табигый зонага муссонлы климат хас?

1. Көнчыгыш Европа тигезлегенең катнаш урманнар зонасына.
2. Яфраклы урманнар зонасына.
3. Ерак Көнчыгышның көньягында урнашкан катнаш урманнар зонасына.

3. Тайга зонасына нинди туфрак хас?

1. Кара туфрак.
2. Көлсу туфрак.
3. Кәсле-көлсу туфрак.

4. Кайсы табигый зонада ылыслы һәм вак яфраклы агачлар белән беррәттән киң яфраклы (имән, өрәңге, юкә һ. б.) агачлар үсә?

1. Тайгада.
2. Катнаш урманнарда.
3. Киң яфраклы урманнарда.

5. Тайга районнарында авыл хуҗалыгының төп юнәлеше — ...

1. Сөт терлекчелеге.
2. Игенчелек.
3. Ит терлекчелеге.

4 нче вариант

1. Нинди табигый зона Россия территориясенең 60% тан артыграгын алып тора?

1. Урман зонасы.
2. Далалар зонасы.

2. Бу зонага түбәндәге үзенчәлекләр хас: озакка сузылган бик салкын кыш һәм кыска салкын җәй, гыйнварның уртача температурасы −30°C, ә июльнеке 0°C, явым-төшемнәр аз (еллык күләме 250 мм дан артмый), көчле җилләр һәм бураннар булып тора. Бу — ...

1. Арктик чүлләр зонасы.
2. Урман-тундра зонасы.

3. Дала зонасына нинди туфрак төре хас?

1. Соры-урман туфрагы.
2. Кара туфрак.

4. Пошн, уссури юлбарысы, кеш, таплы болан, кабарга һ. б. хайваннар нинди табигый зонада яши?

1. Ерак Көнчыгышның көньягындагы катнаш урманнарда.
2. Көнчыгыш Европа тигезлегенең яфраклы урманнарында.

5. Далалар зонасында кайбер хайваннарның (кыргый ат, дүдәк, дала бөркете) юкка чыгуының төп сәбәбе — ...

1. Чамадан тыш күп аулау һәм браконьерлык.
2. Хайваннарның табигый яшәү урыннары кимү.

1 нче вариант

1. Көнчыгыш Европа тигезлеге нигезендә ...

1. Борынгы (кембрийга кадәр барлыкка килгән) платформа ята.
2. Яшь (палеозой вакытында барлыкка килгән) платформа ята.
3. Каледон җыерчыклану өлкәләре урнашкан.

2. Урта Рус калкулыгы барлыкка килүенең сәбәбе — ...

1. Көнчыгыш Европа платформасының фундаменты күтәрелү.
2. Бозлык утырмалары.

3. Көнчыгыш Европа тигезлегенең кайсы өлешендә явым-төшем күләме максималь була?

1. Төньякта.
2. Көньяк-көнчыгышта.
3. Көнбатышта.

4. Көнчыгыш Европа тигезлегенең елгаларына нинди су режимы хас?

1. Кинәт су арту режимы.
2. Язгы ташулы.
3. Җәйге ташулы.

5. Мещера түбәнлеге — ...

1. Борынгы бозлык белән капланмаган тигезлек, һәм аның өсте елга үзәннәре, чокырлар һәм ерымнар челтәре белән кискәләнгән. Ул урман-дала зонасында урнашкан.

2. Зандр тигезлеге, эрегән боз сулары утырмалары туплану нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм аңа бик күп санлы күлләр һәм уйсулык сазлыклар хас. Күбрәк наратлыклар очраса да, ул катнаш урманнар зонасында урнашкан.

2 нче вариант

1. **Көнчыгыш Европа платформасының фундаменты кайсы урында калкан булып җир өстенә чыккан?**

1. Идел буенда.
2. Кола ярымутравында.
3. Көнчыгыш Европа тигезлегенең көнчыгыш өлешендә.

2. **Валдай калкулыгы барлыкка килүнең сәбәбе — ...**

1. Платформаның утырма токымнарында эре җыерчыклар китереп чыгарган процесслар.
2. Бозлык утырмалары.

3. **Көнчыгыш Европа тигезлегенең кайсы өлешендә климатның континентальлеге иң көчле?**

1. Төньякта.
2. Көньяк-көнчыгышта.
3. Көнбатышта.

4. **Идел елгасын туендыручы чыганаклар арасында иң мөһиме — ...**

1. Кар сулары.
2. Яңгыр сулары.

5. **Печора түбәнлеге — ...**

1. Тигезләнгән морена калкулыклары һәм зандр тигезлекләре өстенлек иткән тигезлек. Төньягында яңа бозлык утырмалары очрый. Тигезлекнең күп өлеше тайга зонасында урнашкан.

2. Бозлык астыннан аккан елгалар эшчәнлеге аркасында барлыкка килгән зандр тигезлеге. Монда күлләр һәм сазлыклар күп. Наратлыклар еш очраса да, бу район катнаш урманнар зонасына керә.

3 нче вариант

1. Көнчыгыш Европа тигезлегендә нинди рельеф формалары өстенлек итә?

1. Яссы таулыклар.
2. Түбәнлекләр.
3. Түбәнлек һәм калкулыклар.

2. Каспий буе түбәнлегенең ничек барлыкка килүенең сәбәбе — ...

1. Көнчыгыш Европа платформасы фундаментының тирән һәм бик киң бөгелеше.
2. Эреган боз сулары утырмалары тәэсире.

3. Көнчыгыш Европа тигезлегенә кыш көннәрендә үтеп керүче диңгез һава массалары һава торышын ничек үзгәртәләр?

1. Һава салкыная.
2. Һава җылына.

4. Көнбатыш Двина, Свирь, Волхов, Нева елгалары һәм Ладога, Онега күлләре кайсы бассейнга керә?

1. Төньяк Боз океаны бассейнына.
2. Атлантик океан бассейнына.
3. Эчке агымсулы бассейнга.

5. Валдай калкулыгы — ...

1. Тигезлек һәм аңа мореналы бозлык рельефы хас. Морена калкулыклары күлле иңкүлекләр белән чиратлаша. Күлләр саны 600 дән артык (Селигер күле һ. б.).

2. Тигезлек, өслеге елга үзәннәре, ерымнар һәм балкалар челтәре белән бүлгәләнгән. Урман-дала табигый зонасында урнашкан.

4 нче вариант

1. Көнчыгыш Европа платформасы фундаментының зур өлеше ...

1. Җир өслегенә чыгып тора.
2. Утырма тау токымнары белән капланган.

2. Гомуми Сырт барлыкка килүенең сәбәбе — ...

1. Көнчыгыш Европа платформасының фундаменты күтәрелү.
2. Бозлык утырмалары.

3. Көнчыгыш Европа тигезлегенең зур өлешендә нинди климат өстенлек итә?

1. УКПның уртача континенталь климаты.
2. УКПның кискен континенталь климаты.
3. Субарктик климат.

4. Төньяк Двина, Онега, Печора елгалары һәм Имандра, Кубена күлләре кайсы бассейнга керә?

1. Төньяк Боз океаны бассейнына.
2. Атлантик океан бассейнына.
3. Эчке агымсулы бассейнга.

5. Урта Рус калкулыгы — ...

1. Тигезлек, өслеге елга үзәннәре, ерымнар һәм балкалар белән бүлгәләнгән, урман-дала табигый зонасында урнашкан.
2. Тигезлек, һәм аның күпчелек өлеше океан тигезлегеннән түбәндә ята, ярымчүлләр зонасында урнашкан.

1 нче вариант

1. Урал таулары кайсы тау ясалу чорында барлыкка килгән?

1. Альп тау ясалуы чорында.
2. Мезозой тау ясалуы чорында.
3. Герцин тау ясалуы чорында.

2. Тау сыртларының куэсталы төзелеше нинди тауларга хас?

1. Урал тауларына.
2. Кавказ тауларына.

3. Уралның кайсы өлешендә явым-төшем күләме максималь була?

1. Көнбатыш өлешендә.
2. Көнчыгыш өлешендә.

4. Кавказ тауларының итәкләреннән башлана торган елгаларга нинди су режимы хас?

1. Җәйге ташулы.
2. Язгы ташулы.
3. Кинәт су арту режимы.

5. Түбәндә саналган үзенчәлекләр Урал тауларының кайсы өлешенә хас: Урал тауларының иң түбән өлеше, абсолют биеклекләре 500—800 метрдан артмый, рельефның хәзерге үзгәрүе күбрәк тышкы көчләр тәэсирендә бара; тауларда тайга «патшалык» итә.

1. Төньяк Урал.
2. Урта Урал.
3. Көньяк Урал.

2 нче вариант

1. Абсолют биеклеге буенча Урал тауларының күпчелек өлеше нинди төркемгә керә?

1. Тәбәнәк тауларга.
2. Урта биеклектәге тауларга.
3. Биек тауларга.

2. Бу территориядә химик составы, температурасы һәм башка үзенчәлекләре буенча төрле булган минераль су чыганаклары бик күп. Бу — ...

1. Урал таулары.
2. Төньяк Кавказ.
3. Көнчыгыш Европа тигезлегенең төньяк өлеше.

3. Төньяк Кавказның кайсы өлешендә климатның континентальлеге көчлерәк?

1. Көнбатыш өлешендә.
2. Көнчыгыш өлешендә.

4. Урал тауларының кайсы өлешендә биеклек пояслыгын тулысынча күрергә мөмкин?

1. Поляр алды Уралында.
2. Төньяк Уралда.
3. Көньяк Уралда.

5. Түбәндә саналган үзенчәлекләр Төньяк Кавказның кайсы өлешенә хас: абсолют биеклеге 150 м дан артмый, климаты һәм бик уңдырышлы туфраклары аркасында бу өлкәләрне Россиянең ашлык амбары дип атарга була. Бу — ...

1. Ногай даласы.
2. Кубань буе тигезлеге.
3. Ставрополь калкулыгы.

3 нче вариант

1. Кавказ таулары кайсы тау ясалу чорында барлыкка килгән?

1. Альп тау ясалуы чорында.
2. Мезозой тау ясалуы чорында.
3. Герцин тау ясалуы чорында.

2. Урал тауларының тектоник хәрәкәт нәтиҗәсендә соңгы тапкыр күтәрелүе кайсы тау ясалу чорында булган?

1. Мезозой эрасының триас чорында.
2. Кайнозой эрасының палеоген чорында.
3. Кайнозой эрасының неоген-дүртенчел чорында.

3. Төньяк Кавказның кайсы өлешендә явым-төшем күбрәк була?

1. Көнбатыш өлешендә.
2. Көнчыгыш өлешендә.

4. Төньяк Кавказ елгаларының туену чыганагы буларак нинди сулар өстенлек итә?

1. Җир асты сулары.
2. Бозлык сулары.
3. Яңгыр сулары.

5. Түбәндә саналган үзенчәлекләр Урал тауларының кайсы өлешенә хас: тауларның иң биек өлеше, хәзерге рельефы салкынлыктан ашалу һәм борынгы бозланыш белән билгеләнә. Табигый зона — тау тундрасы, ә тау түбәләрендә мәңгелек кар поясы ята. Бу — ...

1. Поляр Урал.
2. Поляр алды Уралы.
3. Көньяк Урал.

4 нче вариант

1. Россия территориясендә иң озын таулар — ...

1. Сихотэ-Алинь таулары.
2. Кавказ таулары.
3. Урал таулары.

2. Урал тауларының кайсы өлеше рудалы файдалы казылмаларга баерак?

1. Көнчыгыш итәкләре.
2. Субүләр сырт.
3. Көнбатыш итәкләре.

3. Фен дип атала торган күренеш — ...

1. Бик көчле салкын җил һәм ул салкын җил һава массалары үтеп кергәндә барлыкка килә.
2. Җылы һәм коры, кайнар диярлек җил, ул 2500 м лы таулардан төшкән һава массасыннан барлыкка килә.

4. Төньяк Кавказның күпчелек елгалары агымы буенча — ...

1. Тау елгалары.
2. Тигезлек елгалары.

5. Урал тауларының бу өлешендә яссы Урал алды һәм текә битле Урал арты үзенчәлекләре ачык күренә; табигатьтә кеше эшчәнлеге тәэсире яхшы ук күзәтелә. Бу — ...

1. Төньяк Урал.
2. Урта Урал.
3. Көньяк Урал.

СЕБЕР (КӨНБАТЫШ СЕБЕР ТИГЕЗЛЕГЕ, КӨНЧЫГЫШ ҺӘМ ТӨНЬЯК-КӨНЧЫГЫШ СЕБЕР, КӨНЬЯК СЕБЕР ТАУЛАРЫ)

1 нче вариант

1. Көнбатыш Себер тигезлегенең табигый чикләренә горизонт ягын туры китереп җавап бирегез:

Табигый чикләр:	Горизонт ягы:
1. Казах вак таулыгы.	А. Төньякта.
2. Урал таулары.	Б. Көньякта.
3. Енисей елгасы.	В. Көнбатышта.
4. Төньяк Боз океаны.	Г. Көнчыгышта.

2. Байкал алды һәм Байкал аръягы таулары кайсы тау ясалу чорында барлыкка килгәннәр?

1. Альп тау ясалуы чорында.
2. Борынгы Каледон һәм Байкал тау ясалуы чорында.
3. Герцин тау ясалуы чорында.

3. Көнчыгыш Себернең үзәк һәм көньяк өлешләрендә нинди климат тибы өстенлек итә?

1. УКПның уртача континенталь климаты.
2. УКПның континенталь климаты.
3. УКПның кискен континенталь климаты.

4. Себер елгаларының мул сулы булуының төп сәбәбе — ...

1. Мәңгелек туңлык.
2. Явым-төшемнең муллыгы.
3. Парга әйләнүчәнлекнең түбәнлеге.

5. Себернең бу өлешендә ылыслы урманнар өстенлек итә, агач токымнарыннан иң күп таралганы — карагай; туңлык-тайга туфрагы хас. Бу — ...

1. Көнбатыш Себер.
2. Көнчыгыш Себер.
3. Көнбатыш һәм Көнчыгыш Саян таулары.

2 нче вариант

1. Көнчыгыш Себер тигезлегенең табигый чикләренә горизонт ягын туры китереп җавап бирегез:

Табигый чикләр:	Горизонт ягы:
1. Көньяк Себер таулары.	А. Төньякта.
2. Енисей елгасы.	Б. Көньякта.
3. Лена елгасы.	В. Көнбатышта.
4. Төньяк Боз океаны.	Г. Көнчыгышта.

2. Көнбатыш Себер тигезлегенең нигезендә ...

1. Борынгы (кембрийга кадәр барлыкка килгән) платформа ята.
2. Яшь (палеозой вакытында барлыкка килгән) платформа ята.
3. Каледон җыерчыклану өлкәләре урнашкан.

3. Көнчыгыш һәм Төньяк-Көнчыгыш Себер территориясендә кыш көннәрендә нинди һава торышы өстенлек итә?

1. Циклон.
2. Антициклон.

4. Мәңгелек туңлык нинди рельеф формаларын барлыкка китерә?

1. Термокарст күл казанлыкларын һәм бозлы лакколитларны.
2. Морена калкулыкларын.

5. Көньяк Себер таулары территориясендә табигый зоналарның бүленеше нинди законга бәйле?

1. Киңлек зональлеге законына.
2. Биеклек пояслыгы законына.

3 нче вариант

1. Тау системаларына иң биек тау түбәсен туры китереп җавап бирегез:

Тау системасы:	Тау түбәсе:
1. Алтай.	А. Мунку-Сардык тавы.
2. Көнчыгыш Саян.	Б. Җиңү тавы.
3. Черский сырты.	В. Белуха тавы.

2. Көнбатыш Саян тау системасы кайсы тау ясалу чорында барлыкка килгән?

1. Каледон тау ясалуы чорында.
2. Герцин тау ясалуы чорында.
3. Мезозой тау ясалуы чорында.

3. Көнбатыш Себер тигезлеге өчен нинди климат тибы хас?

1. УКПның уртача континенталь климаты.
2. УКПның континенталь климаты.
3. УКПның кискен континенталь климаты.

4. Россия территориясендәге иң зур дельталы елганы атагыз.

1. Лена.
2. Енисей.
3. Индигирка.

5. Көнбатыш Себер территориясендә нинди туфрак тибы өстенлек итә?

1. Арктик һәм тундра-глей туфраклары.
2. Көлсу туфрак.
3. Кәсле-көлсу туфрак.

4 нче вариант

1. Тигезлек исеменә анда өстенлек итүче рельеф формасын туры китереп җавап бирегез:

Тигезлекнең исеме:	Рельеф формасы:
1. Көнбатыш Себер.	А. Яссы таулыгы.
2. Урта Себер.	Б. Калкулыгы.
3. Лена буе.	В. Түбәнлеге.

2. Көнчыгыш Себернең зур өлешенең нигезендә ...

1. Борынгы (кембрийга кадәр барлыкка килгән) платформа ята.
2. Яшь (палеозой вакытында барлыкка килгән) платформа ята.
3. Каледон җыерчыклану өлкәләре урнашкан.

3. Көньяк Себер тауларының зур өлеше өчен нинди климат тибы хас?

1. Субарктик.
2. УКПның континенталь климаты.
3. УКПның кискен континенталь климаты.

4. Кайсы елгаларда иң күп су энергоресурслары тупланган?

1. Көнчыгыш Европа тигезлеге елгаларында.
2. Көнбатыш Себер елгаларында.
3. Көнчыгыш Себер елгаларында.

5. Көнбатыш Себер территориясендә табигый зоналарның урнашуы нинди законга бәйле?

1. Киңлек зональлеге законына.
2. Биеклек пояслыгы законына.

1 нче вариант

1. Ерак Көнчыгышны ни өчен «контрастлар крае» дип атыйлар?

1. Өч сәгать поясында урнашканга.
2. Төньяктан көньякка таба сузылганга.

2. Ерак Көнчыгышның зур өлеше кайсы тау ясалу чорында барлыкка килгән?

1. Герцин тау ясалуы чорында.
2. Мезозой тау ясалуы чорында.
3. Кайнозой тау ясалуы чорында.

3. Ерак Көнчыгышның климатына кайсы океан күбрәк йогынты ясый?

1. Төньяк Боз океаны.
2. Атлантик океан.
3. Тын океан.

4. Ерак Көнчыгыш елгаларының күпчелегенә нинди су режимы хас?

1. Кинәт су арту режимы.
2. Язгы ташулы су режимы.
3. Җәйге ташулы су режимы.

5. Ерак Көнчыгышның бу физик-географик районында мәйданның якынча $2/3$ өлешен яшь җыерчыклы таулар алып тора, тундра һәм урман үсемлекләре өстенлек итә. Монда күп санлы ата торган һәм сүнгән вулканнар, ә көнчыгыш өлешендә Россиядә бердәнбер булган гейзер фонтаннары да очрый. Бу — ...

1. Камчатка ярымутравы.
2. Сахалин утравы.
3. Курил утраулары.

2 нче вариант

1. Камчатка ярымутравын кем ачкан?

1. Витус Беринг.
2. Владимир Атласов.
3. Николай Невельской.

2. Курил утраулары — ...

1. Вулканнар ату нәтиҗәсендә барлыкка килгән утраулар.
2. Материктан аерылып калган утраулар.
3. Коралл утраулары.

3. Ерак Көнчыгышның зур өлешенә нинди климат тибы хас?

1. Субарктик.
2. УКПның кискен континенталь климаты.
3. УКПның муссонлы климаты.

4. Ерак Көнчыгышта мәйданы буенча иң зур күл — ...

1. Кроноцкое күле.
2. Ханка күле.
3. Курил күле.

5. Ерак Көнчыгышның әлеге физик-географик районында иң кырыс климат, районның күп өлеше тундра табигый зонасына керә һәм монда тундра зонасының таулы арктик чүлләре белән аралаша. Бу — ...

1. Приморье крае.
2. Камчатка ярымутравы.
3. Чукотка яссы таулыгы.

3 нче вариант

1. Сахалин утравы белән материкны аерып торучы Татар бугазын кайсы сәяхәтче ачкан?

1. Витус Беринг.
2. Владимир Атласов.
3. Николай Невельской.

2. Сихотэ-Алинь таулары кайсы тау ясалу чорында барлыкка килгәннәр?

1. Герцин тау ясалуы чорында.
2. Мезозой тау ясалуы чорында.
3. Кайнозой тау ясалуы чорында.

3. Җәй көне Приморьеда җилнең төп юнәлеше — ...

1. Коры җирдән диңгезгә таба.
2. Диңгездән коры җиргә таба.
3. Диңгез ярлары буйлап.

4. Ерак Көнчыгышның көньяк өлешендә ага торган елгаларның төп туену чыганагы булган сулар — ...

1. Кар сулары.
2. Яңгыр сулары.
3. Җир асты сулары.

5. Ерак Көнчыгышның әлеге физик-географик районында тәбәнәк һәм урта биеклектәге таулар күп, Тын океанның сейсмик актив өлеше булганга, еш кына җир тетрәүләр күзәтелә; климаты дымлы; территориясенең $^{2}/_{3}$ өлеше урманнар белән капланган. Бу — ...

1. Камчатка ярымутравы.
2. Сахалин утравы.
3. Курил утраулары.

4 нче вариант

1. Россиянең иң көнчыгыш ноктасын кем ачкан?

1. Витус Беринг.
2. Иван Москвитин.
3. Семен Дежнев.

2. Россия территориясендә ата торган иң биек вулкан — ...

1. Алаид вулканы.
2. Ключи Сопкасы вулканы.
3. Кроноцкая Сопкасы вулканы.

3. Кыш көне Приморьеда җилнең иң төп юнәлеше — ...

1. Коры җирдән диңгезгә таба.
2. Диңгездән коры җиргә таба.
3. Диңгез ярлары буйлап.

4. Камчатка ярымутравында һәм Курил утрауларында гына очрый торган туфрак төрен атагыз.

1. Тау-тундра туфрагы.
2. Сазлык туфраклары.
3. Вулканик туфраклар.

5. Ерак Көнчыгышның әлеге физик-географик районы Сихотэ—Алинь тау иленә керә, муссонлы климатлы «Уссури тайгасы» дип атала. Бу —...

1. Приморье крае.
2. Камчатка ярымутравы.
3. Чукотка яссы таулыгы.

«ТАТАРСТАННЫҢ ФИЗИК ГЕОГРАФИЯСЕ» КУРСЫ БУЕНЧА ЙОМГАКЛАУ ТЕСТЫ

1 нче вариант

1. Татарстан территориясенең чик нокталары географик урнашулары буенча кайсы административ районнарга туры килә?

Административ районнар:	Чик нокталары:
1. Балтач районы.	А. Иң көньяк нокта (Хансәяр ав.).
2. Баулы районы.	Б. Иң көнбатыш нокта (Югары Каракитә ав.).
3. Актаныш районы.	В. Иң төньяк нокта (Югары Сәрдек ав.).
4. Чүпрәле районы.	Г. Иң көнчыгыш нокта (Тынламас ав.).

2. Торак пункт исеменең административ-территориаль берәмлек тибына тәңгәллеген ачыклагыз.

Административ-территориаль берәмлек тибы:	Торак пункт:
1. Республика карамагындагы шәһәр.	А. Питрәч.
2. Район карамагындагы шәһәр.	Б. Лаеш.
3. Шәһәр тибындагы поселок.	В. Әлмәт.
4. Авыл.	Г. Мамадыш.

3. Татарстан рельефы өчен кайсы үзенчәлекләр хас?

1. Түбәнлекләр һәм калкулыклар өстенлек итә.
2. Калкулыклар һәм яссы таулыклар күбрәк.
3. Тәбәнәк таулар өстенлек итә.

4. Республика территориясендә иң борынгы утырма токым катламнары ...

1. Кайнозой эрасының антропоген чорына карый.
2. Палеозой эрасының пермь чорына карый.
3. Баулы свитасына (девонга кадәрге утырма токымнарга) карый.

5. Республикадагы күпчелек казылма байлыклар барлыкка килүгә төп сәбәп — ...

1. Магматик токымнар ясалышы.
2. Метаморфик токымнар ясалышы.
3. Утырма токымнар ясалу юлы.

6. Һаваның абсолют температура амплитудасының иң зур булган урыны — ...

1. Кама Тамагы метеостанциясе.
2. Чулпан метеостанциясе.
3. Алабуга метеостанциясе.

7. Республика территориясендә климатның континентальлеге нинди юнәлештә арта бара?

1. Төньяктан көньякка.
2. Төньяк-көнбатыштан көньяк-көнчыгышка.
3. Көньяк-көнбатыштан төньяк-көнчыгышка.

8. Татарстан Республикасының елгалары кайсы океан бассейнына карый?

1. Төньяк Боз океаны бассейнына.
2. Атлантик океан бассейнына.
3. Эчке агымсулы бассейнга.

9. ТРның тулай җир фондының күпчелек мәйданы ...

1. Кәсле-көлсу туфрак.
2. Соры һәм куе соры-урман туфраклары.
3. Кара туфрак.

10. Бу табигый-географик район республиканың иң зур, табигатенең иң күп төрле булуы белән аерыла. Аның составына Камадан көньякка, Иделдән көнчыгышкарак урнашкан территорияләр керә. Бу — ...

1. Идел алды. 2. Кама алды. 3. Кама аръягы.

2 нче вариант

1. Татарстанның административ чикләре өлешчә Россиянең кайсы регионнары чикләренә туры килә?

Регион исеме:	Чикләр:
1. Башкортстан Республикасы.	А. Төньяк-көнчыгышта.
2. Удмурт Республикасы.	Б. Төньяк-көнбатышта.
3. Чуваш Республикасы.	В. Көнчыгышта.
4. Марий Эл Республикасы.	Г. Көнбатышта.

2. Торак пункт исеменең административ-территориаль берәмлек тибына тәңгәллеген ачыклагыз:

Административ-территориаль берәмлек тибы:	Торак пункт:
1. Республика карамагындагы шәһәр.	А. Урыссу.
2. Район карамагындагы шәһәр.	Б. Чистай.
3. Шәһәр тибындагы поселок.	В. Чирмешән.
4. Авыл.	Г. Тәтеш.

3. ТР территориясенең абсолют биек нокталары ...

1. Сарапул калкулыгында.
2. Идел буе калкулыгында.
3. Бөгелмә калкулыгында.

4. ТР территориясенең барлык җирләрендә ...

1. Кайнозой эрасының антропоген чоры катламнары ята.
2. Палеозой эрасының пермь чоры катламнары ята.
3. Баулы свитасы (девонга кадәрге) катламнары ята.

5. Республика икътисады өчен иң мөһим казылма байлык:

1. Нефть. 2. Ташкүмер. 3. Торф.

6. Татарстан Республикасының климат тибы ...

1. Уртача континенталь.
2. Континенталь.
3. Кискен континенталь.

7. Циклоннар Татарстанга күбесенчә кайсы яктан үтеп керә?

1. Төньяк Боз океаны ягыннан.
2. Атлантик океан ягыннан.
3. Тын океан ягыннан.

8. Су режимы буенча Татарстан елгалары нинди типка керә?

1. Кинәт су арту елгалары.
2. Язгы ташулы елгалар.
3. Җәйге ташулы елгалар.

9. Республиканың иң уңдырышлы туфраклары — ...

1. Көсле-көлсу туфраклар.
2. Соры һәм куе соры-урман туфраклары.
3. Кара туфраклар.

10. ТРның әлеге табигый географик районы Идел буе калкулыгында урнашкан һәм «Тау ягы» дип атала. Күп өлеше Зөя бассейнына туры килә, үсемлек капламы буенча район урман-далага карый. Бу — ...

1. Идел алды. 2. Кама алды. 3. Кама аръягы.

3 нче вариант

1. Татарстанның административ чикләре өлешчә Россиянең кайсы чикләренә туры килә?

Регион исеме:	Чикләр:
1. Киров өлкәсе.	А. Көньякта.
2. Ульяновск өлкәсе.	Б. Төньякта.
3. Самара өлкәсе.	В. Көньяк-көнчыгышта.
4. Оренбург өлкәсе.	Г. Көньяк-көнбатышта.

2. Торак пункт исеменең административ-территориаль берәмлек тибына тәңгәллеген ачыклагыз:

Административ-территориаль берәмлек тибы:	Торак пункт:
1. Республика карамагындагы шәһәр.	А. Балтач.
2. Район карамагындагы шәһәр.	Б. Җәлил.
3. Шәһәр тибындагы поселок.	В. Әгерҗе.
4. Авыл.	Г. Бөгелмә.

3. Республиканың хәзерге рельефына тәэсир итүче экзоген көчләрнең иң мөһиме — ...

1. Җил эшчәнлеге.
2. Җир өсте сулары эшчәнлеге.
3. Җир асты сулары эшчәнлеге.

4. ТР территориясендә утырма токымнар катламнарының иң яшьләре кайсы чорда хасил булганнар?

1. Кайнозой эрасының антропоген чорында.
2. Палеозой эрасының пермь чорында.
3. Девонга кадәр (Баулы свитасы).

5. Республика промышленносте өчен әһәмиятле булган нефть ятмалары ...

1. Девон системасына туры килә.
2. Ташкүмер системасына туры килә.
3. Акбур системасына туры килә.

6. Явым-төшемнәрнең максималь өлеше ...

1. Кыш һәм яз айларында күзәтелә.
2. Җәй һәм көз айларына туры килә.

7. Корылыклы, көньяк-көнчыгыштан һәм көньяктан искән эссе, коры җилле җылы һәм эссе һава торышы нинди һава массаларының килеп керүенә бәйле?

1. Диңгезчел урта киңлекләр һавасы.
2. Диңгезчел тропик һава.
3. Континенталь тропик һава.

8. Елгаларның туенуы һәм халыкны су белән тәэмин итү өчен җир асты суларының кайсы катламнары иң әһәмиятле?

1. Девон һәм ташкүмер катламнары.
2. Юра һәм акбур катламнары.
3. Пермь һәм дүртенчел система катламнары.

9. Республиканың күпчелек өлеше нинди табигый зонада урнашкан?

1. Урман зонасында.
2. Урман-дала зонасында.
3. Дала зонасында.

10. Урман белән каплану дәрәҗәсе кайсы административ районда күбрәк?

1. Нурлат районында.
2. Түбән Кама районында.
3. Яшел Үзән районында.

4 нче вариант

1. Мәйданы буенча республикада иң зур административ район — ...

1. Зәй районы.
2. Мамадыш районы.
3. Спас районы.

2. Торак пункт исеменең административ-территориаль берәмлек тибына тәңгәллеген ачыклагыз:

Административ-территориаль берәмлек тибы:	Торак пункт:
1. Республика карамагындагы шәһәр.	А. Теләче.
2. Район карамагындагы шәһәр.	Б. Чаллы.
3. Шәһәр тибындагы поселок.	В. Болгар.
4. Авыл.	Г. Кукмара.

3. Рельеф формаларына аларны хасил итүче тектоник структураларны туры китереп җавап бирегез:

Рельеф формалары:	Тектоник структуралар:
1. Идел аръягы түбәнлеге.	А. Токмов күтәренкелегенең көнчыгыш гөмбәзе.
2. Можга һәм Сарапул.	Б. Татар күтәренкелегенең төньяк гөмбәзе.
3. Бөгелмә калкулыгы.	В. Татар күтәренкелегенең көньяк гөмбәзе.
4. Идел буе калкулыгы.	Г. Казан һәм Мәләкәс батынкылыклары.

4. Татарстанда киң таралыш алган карст формаларын кайсы экзоген көчләр эшчәнлеге хасил итә?

1. Җил эшчәнлеге.
2. Җир өсте сулары эшчәнлеге.
3. Җир асты сулары эшчәнлеге.

5. Кайнозой эрасы (неоген һәм дүртенчел системалар) утырмалары таралган урыннар — ...

1. Калкулык өслекләре.
2. Түбәнлекләр һәм елга үзәннәре.

6. Республика климаты формалашуга нинди һава массалары күбрәк йогынты ясый?

1. Арктик массалар.
2. Урта пояснын континенталь массалары.
3. Континенталь тропик һава массалары.

7. Республика территориясенең уртача еллык явым-төшемнәр күләме кайсы районда күзәтелә?

1. Көнбатыш Кама алдында.
2. Көнбатыш Кама аръягында.
3. Көнчыгыш Кама аръягында.

8. Елгаларның туенуында нинди төр су чыганаклары беренче урында тора?

1. Җир асты сулары.
2. Яңгыр сулары.
3. Кар сулары.

9. Табигый географик зонага биредә киң таралган хайван төрләрен туры китереп җавап бирегез:

Табигый зона:	Хайван төрләре:
1. Урманнар зонасы.	А. Йомран, байбак, җир куяны (кушаяк), дала көзәне.
2. Урман-дала зонасы.	Б. Тиен, ак куян, бурсык, сусар.
3. Дала зонасы.	В. Үр куяны, кабан дуңгызы, кыр кәҗәсе, кыр тычканнары.

10. Татарстанның әлеге табигый географик районы республика территориясенең төньягын алып тора, җир өсте башлыча тигез, тулысынча урманнар зонасына керә. Бу район — ...

1. Идел алды.
2. Кама алды.
3. Кама аръягы.

«ТАТАРСТАННЫҢ ИКЪТИСАДИ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ГЕОГРАФИЯСЕ» КУРСЫ БУЕНЧА ЙОМГАКЛАУ ТЕСТЫ

1 нче вариант

1. Татарстан Республикасында халык санының 1959—1979 елларда тиз үсүе нәрсә белән аңлатыла?

1. Үлүчеләр саны кимү.
2. Туучылар саны арту.
3. Зур промышленность төзелешләре.

2. 1989 елдагы халык санын алу нәтиҗәләре буенча республикада иң зур этник төркем — ...

1. Руслар.
2. Татарлар.
3. Башкортлар.

3. Татарстанда хезмәт ресурслары гомуми халык санының ничә процентын тәшкил итә?

1. 56%. 2. 58%. 3. 68%.

4. Промышленность (сәнәгать) структурасында, аның җитештерелгән продукциясе күләменә карап, нинди тармак өстенлек итә?

1. Азык-төлек промышленносте.
2. Машина төзелеше комплексы.
3. Ягулык-энергетика комплексы.

5. Республикада иң куәтле электр станциясе — ...

1. Казандагы 1 нче номерлы ТЭЦ.
2. Урыссу ГРЭСы.
3. Зәй ГРЭСы.

6. Республикада машина төзелеше үсешенә төп этәргеч — ...

1. Чимал булу.
2. Аңа мохтаҗлык.
3. Квалификацияле кадрлар һәм фән үзәкләре булу.

7. Республикада төп техник культура — ...

1. Рапс.
2. Шикәр чөгендере.
3. Кукуруз.

8. Йөк ташу буенча республика елгалары арасында беренче урында — ...

1. Идел. 2. Кама. 3. Нократ.

9. Административ районнарга икътисади-географик районнарны туры китереп җавап бирегез.

Икътисади-географик районнар:	Административ районнар:
1. Промышленностьлы Идел буе.	А. Алабуга районы.
2. Авыл хуҗалыклы Идел алды.	Б. Аксубай районы.
3. Авыл хуҗалыклы-промышленностьлы Көнбатыш Кама аръягы.	В. Мамадыш районы.
4. Промышленностьлы Көнчыгыш Кама аръягы.	Г. Буа районы.
5. Промышленностьлы Кама буе.	Д. Питрәч районы.
6. Авыл хуҗалыклы Кама алды.	Е. Баулы районы.

10. Әлеге икътисади-географик район төп нефть чыгару районы булып санала. Промышленность тармаклары үсеше нефть һәм табигый иярчен газ чыгаруга бәйле. Үз эченә Әлмәт—Бөгелмә ТПКын кертә. Бу — ...

1. Промышленностьлы Идел буе.
2. Авыл хуҗалыклы Идел алды.
3. Авыл хуҗалыклы-промышленностьлы Көнбатыш Кама аръягы.
4. Промышленностьлы Көнчыгыш Кама аръягы.
5. Промышленностьлы Кама буе.
6. Авыл хуҗалыклы Кама алды.

2 нче вариант

1. Республикада халык саны үсешенең кимүенә төп сәбәп — ...

1. Халыкның табигый үсешенең түбән булуы.
2. Халыкның фәкать читтән килүе («тышкы миграция»).

2. Татар теле нинди телләр төркеменә карый?

1. Иран төркеменә.
2. Төрки телләр төркеменә.
3. Монгол телләре төркеменә.

3. Татарстандагы иң яшь шәһәр — ...

1. Нурлат (Норлат).
2. Азнакай.
3. Баулы.

4. 1975 ел белән чагыштырганда Татарстанда нефть чыгару ...

1. Артты.
2. Кимеде.
3. Бер үк күләмдә калды.

5. Республикада иң эре промышленность берләшмәсе — ...

1. «Казаньоргсинтез» АҖ.
2. «КамАЗ» АҖ.
3. «Нижнекамскшина» АҖ.

6. Химия промышленносте комплексы үзәкләренә аларның урнашу үзәкләрен туры китереп әйтегез:

Химия комплексы предприятиеләре:	Урнашу үзәкләре:
1. «Тасма» АҖ.	А. Казан шәһәре.
2. Фарфор заводы.	Б. Менделеевск шәһәре.
3. Карпов исемендәге химия заводы.	В. Бөгелмә шәһәре.

7. Республика авыл хуҗалыгының терлекчелектә әйдәп баручы тармагы — ...

1. Кошчылык.
2. Сарык асраучылык.
3. Мөгезле эре терлек үрчетү.

8. Республика елгалары арасында пассажирлар һәм туристлар йөртү буенча беренче урында торучы елга — ...

1. Идел.
2. Кама.
3. Вятка (Нократ).

9. Административ районнарга икътисади-географик районнарны туры китереп җавап бирегез:

Икътисади-географик районнар:	Административ районнар:
1. Промышленностьлы Идел буе.	А. Минзәлә районы.
2. Авыл хуҗалыклы Идел алды.	Б. Балык Бистәсе районы.
3. Авыл хуҗалыклы-промышленностьлы Көнбатыш Кама аръягы.	В. Тәтеш районы.
4. Промышленностьлы Көнчыгыш Кама аръягы.	Г. Әтнә районы.
5. Промышленностьлы Кама буе.	Д. Әлки районы.
6. Авыл хуҗалыклы Кама алды.	Е. Лениногорск районы.

10. Әлеге икътисади-географик районда ТР өчен иң куәтле ТПК формалашкан. Специальләшү тармаклары булып нефть химиясе һәм машина төзелеше тора. Авыл хуҗалыгы шәһәр яны хуҗалыгы юнәлешендә үскән һәм шәһәр халкының көндәлек ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән. Бу — ...

1. Промышленностьлы Идел яны.
2. Авыл хуҗалыклы Идел алды.
3. Авыл хуҗалыклы-промышленностьлы Көнбатыш Кама аръягы.
4. Промышленностьлы Көнчыгыш Кама аръягы.
5. Промышленностьлы Кама буе.
6. Авыл хуҗалыклы Кама алды.

3 нче вариант

1. Татарстанда сан буенча күпчелекне ...

1. Шәһәр халкы алып тора.
2. Авыл халкы алып тора.

2. Идел Болгарстанында ислам дине рәсми рәвештә кайсы елда кабул ителгән?

1. 998 елда.
2. 992 елда.
3. 1058 елда.

3. Татар халкының күпчелеге республиканың кайсы төбәкләрендә яши?

1. Көньяк-көнбатыш һәм көньяк районнарында.
2. Эре (зур) елгаларга якын булган урыннарда.
3. Казан артында һәм Көнчыгыш Кама аръягында.

4. Республика халык хуҗалыгының күпчелек кереме ...

1. Ягулык-энергетика комплексына туры килә.
2. Машина төзелеше комплексына туры килә.
3. Төзелеш комплексына туры килә.

5. Машина төзелеше предприятиеләренә аларның урнашу үзәкләрен туры китереп атап чыгыгыз:

Машина төзелеше предприятиеләре:	Урнашу үзәкләре:
1. «Нефтеавтоматика» заводы.	А. Казан шәһәре.
2. «Теплоконтроль» АҖ.	Б. Чистай шәһәре.
3. «Восток» сәгать заводы.	В. Лениногорск шәһәре.

6. Республиканың иң зур азык-төлек промышленносте үзәге — ...

1. Әлмәт шәһәре.
2. Чаллы шәһәре.
3. Казан шәһәре.

7. Республикада чәчү мәйданнары һәм еллык продукциясе буенча беренче урында торган культура — ...

1. Уҗым арышы.
2. Сабан бодае.
3. Арпа.

8. Нефть, газ һәм аларның продуктларын күчерү өчен иң уңае һәм икътисади яктан отышлысы — ...

1. Тимер юл транспорты.
2. Су юллары транспорты.
3. Үткәргеч торба транспорты.

9. Административ районнарга икътисади-географик районнарны туры китереп җавап бирегез:

Икътисади-географик районнар:	Административ районнар:
1. Промышленностьлы Идел буе.	А. Саба районы.
2. Авыл хуҗалыклы Идел алды.	Б. Әгерҗе районы.
3. Авыл хуҗалыклы-промышленностьлы Көнбатыш Кама аръягы.	В. Азнакай районы.
4. Промышленностьлы Көнчыгыш Кама аръягы.	Г. Яңа Чишмә районы.
5. Промышленностьлы Кама буе.	Д. Апас районы.
6. Авыл хуҗалыклы Кама алды.	Е. Югары Ослан районы.

10. Татарстандагы әлеге икътисади-географик районның икътисади нигезен авыл хуҗалыгы (ит-сөт терлекчелеге, сарык асраучылык һәм кошчылык, бөртекле ашлык һәм техник культуралар игү) тәшкил итә. Промышленность тулысынча авыл хуҗалыгы чималын эшкәртүгә һәм төзелеш материалларын чыгаруга юнәлтелгән; ул республикада төп бакчачылык зонасы. Бу — ...

1. Промышленностьлы Идел буе.
2. Авыл хуҗалыклы Идел алды.
3. Авыл хуҗалыклы-промышленностьлы Көнбатыш Кама аръягы.
4. Промышленностьлы Көнчыгыш Кама аръягы.
5. Промышленностьлы Кама буе.
6. Авыл хуҗалыклы Кама алды.

4 нче вариант

1. Халык саны буенча Татарстан Россия регионнары арасында ...

1. 1 нче урында тора.
2. 5 нче урында тора.
3. 7 нче урында тора.

2. Татарстанда русларның күпчелеге кайсы төбәкләрдә яши?

1. Көньяк-көнбатыш районнарда.
2. Зур елгаларга якын булган урыннарда.
3. Казан артында һәм Көнчыгыш Кама аръягында.

3. Хезмәт ресурсларының күпчелек өлеше ...

1. Промышленностьта кулланыла.
2. Авыл хуҗалыгында кулланыла.
3. Төзелеш эшләрендә хезмәт итә.

4. Татарстанның төп экспорт продукциясе — ...

1. «КамАЗ» автомобильләре.
2. Нефть һәм нефть продуктлары.
3. Авыл хуҗалыгы продуктлары.

5. Азык-төлек промышленносте предприятиеләренә аларның урнашу үзәкләрен туры китереп атап чыгыгыз:

Азык-төлек предприятиеләре:	Урнашу үзәкләре:
1. Шикәр заводы.	А. Казан шәһәре.
2. Балык эшкәртү заводы.	Б. Чаллы шәһәре.
3. «Холод» АҖ.	В. Буа шәһәре.

6. ТРда химия һәм нефть химиясе предприятиеләренең иң зурысы һәм бу тармак продукциянең 40% тан артыгын эшләп чыгаручы предприятие — ...

1. «Казаньоргсинтез» АҖ.
2. «Нижнекамскнефтехим» АҖ.
3. «Нижнекамскшина» АҖ.

7. Зур промышленность үзәкләре тирәсендә мөгезле эре терлекчелекнең һәм, гомумән, терлекчелекнең нинди тармаклары үскән?

1. Ит-сөт терлекчелеге.
2. Сөт-ит терлекчелеге.
3. Сарык асраучылык.

8. Татарстанда йөк һәм пассажирлар ташу ягыннан транспортның кайсы төре беренче урында тора?

1. Тимер юл транспорты.
2. Су юллары транспорты.
3. Автомобиль транспорты.

9. Административ районнарга икътисади-географик районнарны туры китереп җавап бирегез:

Икътисади-географик районнар:	Адмнистратив районнар:
1. Промышленностьлы Идел буе.	А. Балтач районы.
2. Авыл хуҗалыклы Идел алды.	Б. Сарман районы.
3. Авыл хуҗалыклы-промышленностьлы Көнбатыш Кама аръягы.	В. Әлмәт районы.
4. Промышленностьлы Көнчыгыш Кама аръягы.	Г. Нурлат районы.
5. Промышленностьлы Кама буе.	Д. Кайбыч районы.
6. Авыл хуҗалыклы Кама алды.	Е. Арча районы.

10. Татарстанның әлеге икътисади-географик районы — ТРның иң алга киткән өлеше. Аның нигезен Казан промышленность үзәге тәшкил итә. Авыл хуҗалыгы шәһәр яны тармагы тибында үскән. Бу — ...

1. Промышленностьлы Идел буе.
2. Авыл хуҗалыклы Идел алды.
3. Авыл хуҗалыклы-промышленностьлы Көнбатыш Кама аръягы.
4. Промышленностьлы Көнчыгыш Кама аръягы.
5. Промышленностьлы Кама буе.
6. Авыл хуҗалыклы Кама алды.


60°
20°
80°
40°
60°
40


80°
100°
120°
140°
160°
к востоку от Гринвича
180°
к западу от Гринвича
60°
Северный полярный круг
40°
100°
120°

«РОССИЯНЕҢ ФИЗИК ГЕОГРАФИЯСЕ» КУРСЫ БУЕНЧА ГЕОГРАФИК НОМЕНКЛАТУРАНЫ БЕЛҮ ДӘРӘҖӘСЕН ТИКШЕРҮ ӨЧЕН БИРЕМНӘР

Контурлы карталарда географик объектларның урынын шартлы билгеләр белән күрсәтегез.

1 нче вариант

Балтыйк диңгезе
Шелихов култыгы
Яңа Җир архипелагы
Печора елгасы
Кубань елгасы
Онега күле
Урта Рус калкулыгы
Эльбрус тавы
Верхоянск сырты
Чукот таулыгы

2 нче вариант

Баренц диңгезе
Обь култыгы
Командор утраулары
Төньяк Двина елгасы
Кама елгасы (Чулман)
Селигер күле
Идел буе калкулыгы
Пайер тавы
Зур Кавказ таулары
Җугҗур сырты

3 нче вариант

Лаптевлар диңгезе
Фин култыгы
Апшерон ярымутравы
Днепр елгасы
Агыйдел елгасы
Байкал күле
Каспий буе түбәнлеге
Ямантау тавы
Черский тау сырты
Путорана платосы

4 нче вариант

Беринг диңгезе
Татар бугазы
Белый утравы
Нева елгасы
Нократ елгасы
Баскунчак күле
Мещера түбәнлеге
Ключи Сопкасы вулканы
Яблоновый сырты
Көнбатыш Саян тау сырты

5 нче вариант

Япон диңгезе
Беринг бугазы
Төньяк Җир архипелагы
Дон елгасы
Иртыш елгасы
Чуд күле
Себер Уваллары
Җиңү тавы
Урта сырт
Алтай

6 нчы вариант

Карский диңгезе
Яңа Себер утраулары

Тамань ярымутравы
Идел елгасы
Тобол елгасы
Ладога күле
Кубань буе түбәнлеге
Константин Ташы тавы
Борщовочный сырты
Көнчыгыш Саян тау сырты

7 нче вариант

Чукот диңгезе
Врангель утравы
Чукот ярымутравы
Урал елгасы
Ангара елгасы
Чаны күле
Төньяк Уваллар
Народная тавы
Байкальский сырты
Юкагир яссы таулыгы

8 нче вариант

Каспий диңгезе
Курил утраулары
Ямал ярымутравы
Обь елгасы
Терек елгасы
Ильмень күле
Ставрополь калкулыгы
Качканар тавы
Сихотэ-Алинь таулары
Витим яссы таулыгы

9 нчы вариант

Көнчыгыш Себер диңгезе
Сахалин утравы
Камчатка ярымутравы
Енисей елгасы
Алдан елгасы
Таймыр күле
Көнбатыш Себер тигезлеге
Пай-Хой сырты
Колыма таулыгы
Анабар платосы

10 нчы вариант

Охота диңгезе
Кола ярымутравы
Таймыр ярымутравы
Лена елгасы
Амур елгасы
Рыбинск сусаклагычы
Урта Себер яссы таулыгы
Поляр алды Уралы
Коряк таулыгы
Тиман кряжы

11 нче вариант

Ак диңгез
Онега култыгы
Франц-Иосиф Җире утраулары
Мезень елгасы
Бия елгасы
Вилюй елгасы
Кулунда күле
Хибин таулары
Базардюзю тавы
Җагды сырты

12 нче вариант

Арал диңгезе
Байдарата култыгы
Канин ярымутравы
Свирь елгасы
Катунь елгасы
Витим елгасы

Балхаш күле
Казах вак таулыгы
Белуха тавы
Смоленск-Мәскәү калкулыгы

13 нче вариант

Азов диңгезе
Пенжина култыгы
Вайгач утравы
Волхов елгасы
Ташлы Тунгуска елгасы
Шилка елгасы
Ыссык-Күл
Ока-Дон тигезлеге
Тәлпозиз тавы
Становой сырты

14 нче вариант

Кара диңгез
Челюскин борыны
Колгуев утравы
Кура елгасы
Чусовая елгасы
Зайсан күле
Колыма елгасы
Полесье түбәнлеге
Мунку-Сардык тавы
Төньяк Байкал таулыгы

15 нче вариант

Хатанга култыгы
Канин борыны
Кырым ярымутравы
Прут елгасы
Түбән Тунгуска елгасы
Аргунь елгасы
Ханка күле
Көнчыгыш Европа тигезлеге
Казбек тавы
Сетте-Дабан сырты

16 нчы вариант

Двина култыгы
Карский Капкасы бугазы
Көньяк Буг елгасы
Ока елгасы
Яна елгасы
Эльтон күле
Төньяк Себер түбәнлеге
Поляр Урал
Становое таулыгы
Васюган тигезлеге

17 нче вариант

Чеша култыгы
Босфор бугазы
Алеут утраулары
Днестр елгасы
Хатанга елгасы
Уссури елгасы
Алтынкүл
Кузнецк Алатавы
Лена буе платосы
Патом таулыгы

18 нче вариант

Енисей култыгы
Вилькицкий бугазы
Десна елгасы
Мәскәү елгасы
Зея елгасы
Анадырь елгасы
Ишим тигезлеге
Салаир кряжы
Урта Урал
Сунтар-Хаята сырты

19 нчы вариант

Чаун култыгы
Лаперуза бугазы
Медведица елгасы
Эльба елгасы
Бурея елгасы
Сыр-Дәрья елгасы
Бараба түбәнлеге
Енисей кряжы
Үзәк Якутия түбәнлеге
Бырранга таулары

20 нче вариант

Петр Великий култыгы
Дежнев борыны
Дмитрий Лаптев бугазы
Селенга елгасы
Аму-Дәрья елгасы
Таз елгасы
Гомуми Сырт
Төньяк Урал
Алдан таулыгы
Бурея сырты

ЭЧТӘЛЕК

Россиянең географик урыны һәм чикләре........ 3
Россия территориясен юучы диңгезләр........ 8
Россия территориясенең рельефы, геологик төзелеше һәм файдалы казылмалары........ 12
Россиянең климаты........ 20
Россиянең эчке сулары һәм су ресурслары........ 27
Россиянең туфраклары һәм туфрак ресурслары........ 35
Россиянең табигый зоналары........ 39
Көнчыгыш Европа тигезлеге........ 43
Төньяк Кавказ. Урал........ 47
Себер........ 51
Ерак Көнчыгыш........ 55
«Татарстанның физик географиясе» курсы буенча йомгаклау тесты........ 59
«Татарстанның икътисади һәм социаль географиясе» курсы буенча йомгаклау тесты........ 66
«Россиянең физик географиясе» курсы буенча географик номенклатураны белү дәрәҗәсен тикшерү өчен биремнәр........ 76

Учебное издание

Саубанова Лилия Ильгизовна
Тайсин Анвар Сафович

ТЕСТЫ ПО ГЕОГРАФИИ РОССИИ

Для 8 класса татарской средней
общеобразовательной школы

(на татарском языке)

Редакция мөдире *Л. Х. Мөхәммәтҗанова*
Редакторлары *Р. С. Вафина, Р. З. Закирова*
Бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Тышлык рәссамы *Ю. А. Щетинина*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Р. М. Галимова*
Корректоры *Г. Р. Мифтахова*

Нәшриятка 183 нче номерлы лицензия 1997 елның 7 апрелендә бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 5.02.2003. Форматы $60 \times 90^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 5,0.
Нәшер-хисап табагы 2,07. Тиражы 6 200 д. Заказ З-111.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.

http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.